ЧАБА ПОЕЗД...
«ВТ» хәбәрчесе «яшьлек поезды»на утырып Мәскәүгә барып кайтты
> 3

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре
> 6

КАНАТЛЫ КАЗАН
Яңа юл кайчан төзеләчәк?
> 9

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ
Балалар уенчыкларына ГОСТ таләпләре кертелә
>10

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 22 (29182) | Сишәмбе | 20 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТАТАРСТАН ОЛИМПИАДАСЫ

КАЗАНДА «КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ» ФИДЖИТАЛ-ТУРНИРЫ БАШЛАНДЫ

Спорт кына түгел бу!

Спорттагы яңа сәхифә. Тарихта тәүге мәртәбә оештырыла торган «Киләчәк уеннары» халыкара турниры ярышлары башланды. Ни өчен аны яңа Олимпиада дип атыйлар? Башкала әзерме? Ярышларны гел Казан кабул итәчәкме? Зур спорт бәйрәме алдыннан, оештыручылар белән күзгә-күз күрешеп, шул сорауларга җавап алдык.

Афина кебек Казан

Үз чорында Афина шәһәре Олимпия уеннары башлангыч алган урын булган кебек, Казан да «Киләчәк уеннары» ватаны булып тарихка кереп калачак. Шәһәр мэры Илсур Метшин турнирга әнә шундый якты өметләр баглый.

– Казан өчен спорт дөньясы үзәгендә булу ят күренеш түгел, – диде Илсур Метшин. – Кайчандыр Афинада Олимпиада барлыкка килгән кебек, бездә дә яңа, санлы (цифровая. – **Авт.**) Олимпиада туачак. Без бу чарага чын күңелдән сөенәбез. Зур ярышлардан соң шәһәрдә нинди дә булса мирас кала. «Киләчәк уеннары» өчен билгеләнгән барлык инфраструктура – безнең алдарак үткәргән дөнья чемпионатлары һәм башка чараларның мирасы.

Илсур Метшин сүзләренчә, спортның яңа сәхифәсе берәүне дә битараф калдырмаячак.

– Ярыш мәйданчыкларында дөньяның төрле почмакларыннан бер-берләренә бөтенләй охшамаган кешеләр очраша, дуслаша. Милләтләр, диннәр, телләр аеру юк. Киләчәк дөньябыз сурәте әнә шул инде, – диде шәһәр мэры.

Сүз уңаеннан, оештыручылар Уеннарга 80 меңнән артык билет чыгарган булган. Шуның 77 меңе инде сатылып беткән. Искәртеп үтик: «Киләчәк уеннары»ның тантаналы ачылышы чәршәмбегә тәгаенләнгән. Аны «Беренче канал» күрсәтәчәк. Тамашачыларга 18.45 сәгатькә телевизор экраны каршына җыелырга киңәш итәләр.

«Киләчәк уеннары» – саннарда

- Ярышларда 107 илдән 2 меңгә якын кеше катнаша.
- Турнир 21 юнәлештәге ярышлардан гыйбарәт.
- Барлыгы 107 илдән 6 меңләп кунак килер дип көтелә.
- 19 гыйнварда узган тәүге ярышларны онлайн рәвештә 7 миллионнан артык кеше караган.

dspkazan.com

«Киләчәк уеннары» турниры 3 мартка кадәр дәвам итәчәк.

Сабан туе түгел лә

Ачык чырай, такта чәй. Татарстан һәм аның башкаласы спортчыларны да, туристларны да, рәсми затларны да үзенә генә хас кунакчыллыгы белән каршы алырга әзер. Шәһәр мэры Илсур Метшин моны саннар белән дә раслады.

– Без кабул иткән ярышларның берсен алып, икенчесен куярлык түгел. Без кунакларны каршы алабыз, аларның кутәренке кәефе, тук тамагы өчен җавап бирәбез, – ди шәһәр мэры. – Волонтерлар, кунаклар белән бергә, Уеннарга 6 меңләп кеше киләчәк. Алар өчен 33 кунакханә, кунакханәләрдә 2,6 мең урын әзерләнде. Универсиада авылында тагын 1,2 мең урын. Кунакларны шәһәребезнең 300ләп кафе-рестораны көтә. Катнашучыларга һәм хөкемдарларга – 50 мең, волонтерлар өчен 40 мең өлеш ризык әзерлибез.

Рух турында да онытмыйлар. Илсур Метшин сүзләренчә, Казанда кунаклар өчен 100гә якын мәдәни чара оештырылачак. Кыскасы, кунаклар күреп, татып, авыз итеп, тыңлап, сокланып, Татарстан һәм Казан турында күп нәрсә белеп кайтып китәчәкләр дигән өметтә.

Әле ярыш башланырга да өлгермәде, журналистлар инде аның киләчәге турында кызыксынды. Турнирны даими рәвештә Казанда гына үткәрү мөмкинме?

– «Киләчәк уеннары» – Сабан туе түгел. Һәр шәһәр, һәр ил нииндидер яңалык алып килә. Киләчәктә, берникадәр вакыт узгач, Казан кабат бу Уеннарны кабул итәр, дип ышанабыз. Әмма киләсе 10 елда түгел, – дип җавап бирде бу сорауга Илсур Метшин.

Тагын 10 ел көткәнче, бер кат күреп калсак яхшырак шул. Хәерле сәгатьтә!

СҮЗ УҢАЕННАН

Россия Президенты Владимир Путин ил төбәкләре буенча эшлекле сәфәрләр оештырырга ниятли. Дәүләт башлыгы сәфәр кылган урыннарның берсе Казан булырга мөмкин. «Мәскәү. Кремль. Путин» тапшыруы хәбәр иткәнчә, ил Президенты «Киләчәк уеннары»ның тантаналы ачылышында катнашырга мөмкин. Искәртеп үтик: соңгы тапкыр дәүләт башлыгы Татарстан башкаласына 2019 елда килгән иде. Бу вакытта ул «WorldSkills Kazan» дөнья чемпионатын ябу тантанасында кунак булды.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Хәрбиләргә – ярдәм

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен Россия Президенты Указы белән оешкан «Ватанны саклаучылар» фондына 18 миллиард сумнан артыграк күләмдә грант биреләчәк. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин әйтүенчә, акча хәрбиләргә дарулар һәм техник реабилитация чаралары сатып алу, документларны ясату, укыту, яңа һөнәргә өйрәтү, эшкә урнаштыру өчен тотылачак.

Хөкүмәт башлыгы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына акчаның ничек тотылганын күзәтеп торырга кушкан. «Ватанны саклаучыларга ярдәм итү – безнең гомуми бурыч. Аны үтәүгә бик җаваплы карарга кирәк», – дигән Мишустин.

Дүрт көн кунак

Узган елда Казанда 4 миллион чамасы турист булып киткән. Алар бездә барлыгы 38 миллиард сум акча тоткан. Алдагы елдагыга караганда 22,3 процентка зуррак сан бу.

Казанның Туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова әйтүенчә, Татарстан башкаласында сәяхәтчеләрнең көндәлек чыгымы бер кешегә уртача 2,75 мең сум (2022 елдагыга караганда 34 процентка күбрәк) тәшкил иткән. Алар бигрәк тә кафе, бар һәм рестораннарда акчаны күп тоткан. Кунакларның җәмәгать туклануы урыннарындагы чыгымнары барлыгы 4,4 миллиард сум (48 процентка арткан) тәшкил иткән. Туристлар азык-төлек кибетләрендә бер кергәндә уртача – 695 сум, кафе, ресторан һәм барларда – 864 сум, күңел ачуга – 1256 сум, кунакханәләргә 6351 сум акча сарыф иткән.

Дарья Санникова сүзләренә караганда, Казанга туристлар башлыча май аеннан ноябрьгә кадәр килә. Сәяхәтләрнең 70 процентан артыграгы шушы чорга карый. Безгә килүчеләрнең 60 процентан күбрәге – хатын-кызлар. Аларның уртача яше – 40. Сәяхәтчеләр бездә уртача 4 көн кунак була.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кыйммәтле метр

Казан соңгы 5 ел эчендә бер бүлмәле фатирны арендалау бәяләре буенча шәһәрләр рейтингында алтынчы урынга чыккан. Белгечләр мәгълүматларына караганда, 2019 елдан бирле безнең шәһәрдә бер бүлмәле фатирга аренда хакы 63 процентка артып, 16,4 меңнән 26,7 мең сумга җиткән.

Мондый фатирларны арендага алып тору хакы Түбән Новгородта бигрәк тә нык кыйммәтләнгән (94 процентка). Биредә аренда бәясе 14,4 мең сумнан 28 мең сумга кадәр күтәрелгән. Чиләбе әлеге рейтингта икенче урынга чыккан. Бу шәһәрдә аренда хакы 93 процентка үсеп, 22,2 мең сум (элегрәк 11,5 мең сум булган) тәшкил иткән. Ростов-Дон өченче урынга чыккан (үсеш – 78 процент: 15,3 меңнән 27,2 мең сумга менгән). Исемлектә Омск бишенче урынны алган.

Яңалык

Табиблар язы

Быелгы язны кар көртләреннән түгел, медицина тармагы хезмәткәрләре дә зарыгып көтә. Россия Президенты Владимир Путин 1 марттан кечкенә шәһәрләр, район үзәкләре һәм авылларда эшләүче белгечләргә айлык түләүләрне күтәрергә тәкъдим итте. Моннан тыш, 1 апрельдән барлык ак халат ияләренең хезмәт хакының оклад өлеше 50 процентка кадәр артачак, дип көтелә.

Рәсми мәгълүматларга караганда, кечкенә шәһәрләр һәм авылларга бәйле яңалык илдәге 210 меңнән артык медицина тармагы хезмәткәренә кагылачак. Әлеге максаттан гына да федераль үзәктән 57 миллиард сумга якын акча бүлеп биреләчәк, дип белдергән Ил Хөкүмәте Рәисе урынбасары Татьяна Голикова.

1 марттан акча кемнәргә һәм күпмегә арта?
– **50–100 мең** кеше яшәгән шәһәрләрдә табиблар төп хезмәт хакыннан тыш өстәмә рәвештә – **29 мең сум**, урта медицина персоналы **13 мең сум** акча алачак.
– **50 меңнән кимрәк** халык яшәгән торак пунктларда әлеге түләүләр табибларга – **50 мең сум**, урта медицина персоналына 30 мең сум тәшкил итәчәк.

Айлык акчаның оклад өлешенә килгәндә, бүген әлеге күрсәткеч ил күләмендә 40 процент чамасы тәшкил итә, ди. Ягъни эш бирүче хезмәт хакының әнә шулкадәр өлешен генә бернигә карамастан тулысынча түли. Калганы исә һәр төбәктә, хәтта аерым медицина оешмасында төрлечә исәпләнергә мөмкин. «Өстәмә түләүләр мөһим, әлбәттә. Әмма медицина тармагы хезмәткәрләре хезмәт хакының оклад өлешен арттыру яклы», – диде Илбашы узган атнада узган чараларның берсендә. Ул 1 апрельдән ак халат ияләренең хезмәт хакының оклад өлешен 50 процентка кадәр арттырырга, шул ук вакытта өстәмә түләүләрне саклап калырга кушты.

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Безгә беренчел звенодан алып әйдәп баручы клиникалар һәм институтларга кадәр бөтен системаны халыкның сәламәтлеген саклауга үзгәртеп корырга кирәк. Сәламәтлек саклау системасының үзәгендә күрсәтелгән хезмәтләр саны түгел, ә кеше һәм аның сәламәтлеге торырга тиеш.

– Яңалык турында ишеттек, үзара сөйләшеп тә алдык инде, – ди Яшел Үзән медицина көллиятен тәмамлап, районда шәфкать туташы булып эшкә урнашкан Гөлзирә Вәлиева. – Айлык акчам 20–25 мең сум чамасы. Яшь белгеч буларак, өстәп 900 сум түлиләр. Эшебез бик катлаулы. Көне буе авырулар белән эшләргә, даими рәвештә белемне дә камилләштереп торырга кирәк. Җаваплылыгына күрә акчасы аз дип, яшьләр тармакка килергә ашыкмый. Хезмәт хакларын арттырсалар, вазгыять тә үзгәрәчәк.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин хәбәр итүенчә, республикада табибларның уртача хезмәт хакы 104 мең сум тәшкил итә. Шәфкать туташлары – 53 мең сум, ә санитарлар 38 мең сум акча ала. Былтыр сәламәтлек саклау тармагына 409 табиб эшкә килгән.

Сүзгә-сүз

er.ru

Ольга КАЗАКОВА, Россия Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты җитәкчесе:

Бүген мәктәп бинасында Россия дәүләт флагы булу мәҗбүри. Ә менә балалар бакчасы, көллият, университет кебек башка белем бирү учреждениеләре өчен бу – хокук, тик бурыч түгел. Дәүләтнең төп символы һәр белем бирү оешмасында булырга тиеш. Ул балалар һәм яшьләр арасында ватанпәрвәрлек хисен арттыра.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ТЕЛЕФОН МОШЕННИКЛЫГЫ

Россиялеләрнең күпчелеге (88%) телефон мошенникларыннан шалтыратулар яисә смс-хәбәрләр кабул иткән. 10 проценты, гомумән, шулар аркасында акчасын югалткан. «Диалог Регионы» агентлыгы, сораштыру уздырып, шуны ачыклаган.

МОШЕННИКЛАР КЕМ БУЛЫП ШАЛТЫРАТА?



Банкның иминлек хезмәте	69%
Хокук сакчылары һәм дәүләт органнары хезмәткәрләре	65%
Бәлагә тарыган туганнар	21%
Маркетплейсларда эш тәкъдим итәләр	19%
Лотереяда җиңүче булу турында хәбәр итәләр	16%

Сату-алу туктамый

Республикада быел гыйнвар аенда торак сату-алу буенча 7177 килешү теркәлгән. Росреестрның Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, аларның 2368е Казанга туры килә. Башкалабызда 2131 килешү (җир кишәрлекләрен сатып алу буенча килешүләр дә шушы исәпкә керә) банк ипотекасыннан файдаланып төзелгән. Елның беренче аенда Татарстанда ипотека ярдәмендә барлыгы 6095 алыш-биреш (җир кишәрлекләрен дә кертеп) теркәлгән.

Узган айда республикада җир кишәрлекләрен сату-алу буенча 8467 килешү имзаланган. Шул исәптән Казанда – 1058.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

РЕЦЕССИЯ ЗУР СУГЫШКА КИТЕРӘ

Дөнья икътисадында түбәнәю билгеләре атнадан-атнага ешрак күренә. Ниһаять, Бөекбритания рецессиягә кереп бара дигән рәсми хәбәр дә килеп иреште. 2023 елның октябрь – декабрь айларында ил икътисады 0,3 процентка кысылды, ди рәсми чыганаклар. Эчке тулай продуктның кимүе өченче кварталда 0,1 процент булган. Ике квартал рәттән түбәнәю рецессия дип атала. Рецессия инде зур кризисның башлануын хәбәр итә.

Германия икътисадында 2024 елга бернинди дә алгарыш көтелми. Немецларда җитештерүнең түбәнәюе беренче булып башланды һәм быел түбәнәю 0,5 процент булыр дип саныйлар. Шуңа охшаш хәл Франциядә һәм Европаның башка илләрендә дә күзәтелә. Берничә кечкенә ил генә үсештә, әмма аларның үсеше глобаль икътисадка берничек тә тәэсир ясамый. Нидерланд, мәсәлән, үткән ел 0,1 процентлык үсеш күрсәткән. Әмма үсеш темпы 43 тапкыр кимегән. Нидерландлыларның бер кризиста да андый түбән нәтиҗә күрсәткәне булмаган. 1975 елдан соң, ягъни соңгы илле елга якын вакыт эчендә бу алар өчен иң начар күрсәткеч.

Популист Милейны Президент итеп сайлаган Аргентинада сәнәгать җимерелеп бара. Декабрь аенда сәнәгать җитештерүе 5 процентка кимегән. Япония – тискәре процент ставкаларын саклаган бердәнбер ил – шулай ук рецессиягә кереп бара. Японнар үткән гасырның туксанынчы елларыннан бирле торгынлыкта инде: рәтле-башлы үсеш күрсәтә алмыйлар. Икътисадның торгынлыгын хәтта «япон чире» дип атап йөртә башладылар. Күпләп акча басып бушка өләшү япон икътисадына булышмый.

Белгечләр, Кытайда да «япон чире» башланып килә, диләр. Рәсми чин статистикасы саллы гына үсеш күрсәтә күрсәтүен, әмма, бердән, ул үсеш Күк асты иле өчен җитәрлек түгел, икенчедән, хөкүмәтнең зур күләмдә акча басып өләшүе хисабына гына бара. Илдән чит ил инвестицияләре качып бетеп килә. Фонд базары җимереклек хәлендә. Торак базарын сазлыктан чыгарырлык түгел. Барысы бергә җыелып болар торгынлыкка китерәчәкләр. Японнардан аерма шунда: Кояш чыгышы иле стагнациягә бай хәлдә килеп керде, шуңа чагыштырмача җиңел кичерде. Кытайда барысы да киресенчә.

Бер АКШ икътисады гына әлегә үсеш күрсәтә. Бу американнарның күпләп чимал сатуына бәйле. Әмма аларда банк түнтәрелешләре бара һәм дәүләт әҗәте кызу темплар белән үсә. Дөнья икътисадында мондый проблемалар беренче тапкыр гына түгел инде. Әмма бу юлы аларның чишелеше юк. Шуңа күрә Азәрбайҗан Президенты Илһам Алиевның үткән атнада: «Дөнья Өченче бөтендөнья сугышына бик якын», – дигән белдерүенә игътибар итәргә туры килә.

Россиядә

ДӘҮЛӘТ ХУҖАГА ӘВЕРЕЛГӘНДӘ

Россиядә рәсми оптимизм бик көчле. Мәскәү башланып килүче елда үсеш көтә. Статистика, теләсә, үсешне күрсәтә алачак, әлбәттә. Әйтик, үткән атнада доллар янә 93 сумга кадәр сикерде. Долларның күтәрелеше Илкүләм байлык фондының сумнардагы күләмен арттыра. Фондтан акча аласың, кимү урынына ул арта.

Доллар күтәрелгәч, импорт товар бәяләре дә артмый кала алмый, үзебез җитештергәне дә шуңа ияре. Узып та китә әле кайчак. Бер импорт товарның да йомырка үсеше кадәр бәя артуы күрсәтә алганы юк. Бәя арту бюджетка салым булып әйләнеп кайта, бюджетта дефицит кими – безнең кесәләрдә арта. Статистика бер дә алдашмыйча үсеш күрсәтә мондый чакта.

Рәсми саннарда бездә дә төшенкелек күзәтелә барыбер. Бөтен дөньяда икътисад ишелеп, безнеке генә тотрыклы калса, могҗиза булыр иде. «Росморречфлот» дигән оешма, Россия портларында товар әйләнеше гыйнвар аенда декабрь белән чагыштырганда гына түгел, үткән елның шул чоры белән чагыштырганда да 6,2 процентка кимеде, дип белдерә. Бар төр йөк ташу да һәм барлык портларда да кими. Ерак Көнчыгыш портларында кимү – 9,1 процент. Кызыл диңгез аша үтеп Санкт-Петербургка һәм Новороссийскийга килүче товарлар шулай ук кимегән. Йәмән гыйсъянчылары Россия корабларына тимәскә вәгъдә итә итүен, әмма, бердән, бәласеннән башаяк, икенчедән, йөк ташуның кимүе башка сәбәпләргә дә бәйледер, мөгаен.

Россиянең авыл хуҗалыгында рентабельлек кими. Бигрәк тә үсемлекчелек тармагында. Дөресен генә әйткәндә, авыл хуҗалыгы беркайчан да рентабельлек белән мактана алмады. Субсидияләр хисабына гына бераз уңай нәтиҗә күрсәтеп килде. Бар нәрсәгә бәя күтәрелгәндә һәм чыгымнар үскәндә, рентабельлек артса, гаҗәп булыр иде. Белгечләр авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр түбән торганда, җитештерүчеләрнең банкротлыгы башланмагае, диләр.

Авыл хуҗалыгы гына түгел, хәтта оборона сәнәгатенә хезмәт итүче гражданлык сәнәгате тармакларында да үткән елгы кискен күтәрелештән соң, быел торгынлык башлануы мөмкин. Владимир Путин Уралга визиты вакытында Чиләбе электрометаллургия заводын тиктомалдан гына дәүләт кулына тартып алмады. Эре предприятиеләрнең хуҗасы алышына, алар дәүләт кулына күчәчәк дигән фаразлар тормышка ашып килә. Дәүләт алар алдында торган проблемаларны ничек чишәр – анысы башка мәсьәлә.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

АКЧА БАКЧАДА ҮСМИ

4 триллион сумлык чик, хезмәт хаклары, эшче көчләргә кытлык һәм уртак тырышлык. Башкалада республиканың социаль-икътисадый үсешенә багышланган утырыш узды. Сөйләшер сүз күп җыелган: чара дүрт сәгатькә якын дәвам итте. Анда яңгыраган фикерләрне «ВТ» хәбәрчесе дә тыңлады.



tatarstan.ru

Татарстанда социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб, Икътисад министрлыгының еллык коллегиясе һәм Дәүләт Думасының Икътисадый сәясәт комитетының күчмә утырышы узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Былтыр ирешкән төп саннарны Премьер-министр урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов җиткерде. Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанда тулай төбәк продукты 4,1 триллион сум тәшкил иткән. Министр әйтүенчә, барлык чикләүләр, санкцияләр, кадрлар дефициты, кредит-акча сәясәтен катгыйландыруга да карамастан, Татарстан предприятиеләре үсүен дәвам иттерә.

– Моңа кадәр тупланган ныклык запасы, кече һәм урта предприятиеләрнең өзлексез эше, барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының үзара килешеп эшләве һәм дәүләттән ярдәм чараларын тормышка ашыру бәрабәренә 2023 елда республикада тулай төбәк продукты күрсәткече 4 триллион сумлык чикне узды, – диде Мидхәт Шаһиәхмәтов.

Аның әйтүенчә, төп капиталга инвестицияләр күләме былтыр 1 триллион сумнан да артып киткән. Төзелеш эшләре күләме 15 процентка үсеп, 708 миллиард сумга җиткән. Узган елның гыйнвар – ноябрь айларына алынган мәгълүматларга караганда, Татарстан оешма-предприятиеләрендә уртача хезмәт хакы 59994 сум тәшкил иткән. Әлеге күрсәткеч буенча республика Идел буе федераль округында беренче урында тора. Чагыштыру өчен, 2022 елда Татарстанда уртача хезмәт хакы – 52274 мең сум, 2021 елда – 45800 сум булган. Иң күп уртача хезмәт хакы алучылар – казылма байлыклар чыгару (94,6 мең сум), мәгълүматлаштыру һәм элемтә (92,4 мең сум), финанслау һәм иминият эшчәнлеге (86,4 мең сум) тармакларында эшли.

Билгеле булганча, Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе иң түбәннәрдән берсе, ул 0,3 процент тәшкил итә. Утырышта хәбәр итүләренчә, Татарстанда 4,3 мең кеше рәсми рәвештә эшсез булып теркәлгән. 2024 елның 1 гыйнварына эш бирүчеләр барлыгы 48,7 мең вакансия урнаштырган. Былтыр мәшгульлек үзәкләренә төрле сораулар белән 92 меңгә якын кеше мөрәҗәгать иткән. Шул исәптән 30 мең кешене, эш эзләүче буларак, исәпкә алганнар. 2023 елда 22 мең кешене эшкә урнаштырганнар.

Рәсми мәгълүматларга караганда, Татарстанда 293,9 мең үзмәшгуль бар. 2023 ел башы белән чагыштырганда, аларның саны 69 мең кешегә диярлек арткан. Республикада кече һәм урта эшкуарлыкка булышу йөзеннән күпсанлы ярдәм чаралары тормышка ашырыла.

– Узган ел дәвамында кече һәм урта эшкуарлыкка 87 миллиард сумлык ярдәм күрсәтелде, – диде министр.

2024 елның 1 гыйнварына Татарстанда 172,5 мең кече һәм урта эшкуарлык субъекты теркәлгән. Аларның зур өлеше, ягъни 38,3 проценты сәүдә юнәлешенә туры килә. Шулай ук төзелеш һәм логистика (һәркайсы 10 процент) кебек юнәлешләр дә киң таралган. Бизнес тармагында 612 меңгә якын кеше эшли.

Чарага федераль дәрәҗәдәге кунаклар да күп чакырылган иде. Алар бүгенге хәлгә генә бәя биреп калмыйча, күбрәк алда көткән эшләр турында сөйләде. «Авырткан җир»гә кагылгангамы, залда утыручылар Дәүләт Думасының Икътисадый сәясәт комитеты җитәкчесе Максим Топилинның тәкъдимен алкышларга күмде. Мәскәү кунагы кадрлар кытлыгы мәсьәләсенә тукталды.

– Эшче көчләр җитмәү турында күп әйтелде. Бу федераль дәрәҗәдә дә фаразланды. Төрле чаралар күрелде, – диде Максим Топилин һәм гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә тукталды. – Хезмәт законнары бар, алар бик консерватив. Еш кына аны үзгәртергә тырышу бик авыр, хәтта куркыныч та. Чынлыкта исә куркырга кирәкми, сак эш итә белергә кирәк. Мөмкинлекләр бар, без бу юнәлештә эшләячәкбез.

Сөйләшүгә Рөстәм Миңнеханов йомгак ясады. «Республиканың икътисадый үсеше ул – предприятиеләр һәм республикадагы хакимият органнарының федераль хезмәттәшләр, ведомстволар белән берлектә башкарган хезмәте нәтиҗәсе», – диде Татарстан Рәисе. Ул федераль Хөкүмәткә ярдәмнәре өчен рәхмәт тә белдерде.

– Республикада булган һәрнәрсә, ирешелгән барлык икътисадый нәтиҗәләр – безнең уртак эшебез. Федераль Хөкүмәт, Президент тарафыннан зур ярдәм алабыз. Без бик тыгыз эшлибез. Республиканың Икътисад министрлыгына һәм, әлбәттә, җитештерүчеләребезгә дә рәхмәт белдерәсем килә. Безнең югары нәтиҗәләрдә хезмәт коллективларының, җитәкчеләренең өлеше зур, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БУЙ ҖИТМӘСЛЕК ТҮГЕЛ

Арчалылар нишләп ята? Нинди уңышларга ирешкәннәр дә нинди җитешсез яклары бар? Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин район советы утырышында катнашты.

Районның 2023 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2024 елга бурычлары белән Арча районы башлыгы Илшат Нуриев таныштырды. Аның чыгышының бер өлеше махсус хәрби операциягә багышланган иде. Ул хәзерге көндә Ватанны саклаучы районидашларын, аларга һәм гаиләләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында сөйләде.

– Райондашларыбыз фронтның алгы сызыгында үз-үзләрен аямыйча хәрби бурычларын үти. «Батырлык ордены» белән – сигез, «Батырлык өчен» медале белән биш егетебез бүләкләнде, – диде ул. – Арча халкы якташларыбызга, илебезнең яңа территорияләрендә яшәүчеләргә актив ярдәм итә. Гуманитар ярдәмнең гомуми күләме 172 тоннага җитте.

Авыл хуҗалыгы – район икътисадында төп тармакларның берсе (36,3 процентны тәшкил итә). Илшат Нуриев сүзләренчә, төп юнәлешләр – сөт, ит җитештерү, бөртекле һәм техник культуралар, бәрәңге үстерү.

– Әлеге тармак барлык юнәлешләр буенча да үсештә, – диде ул, санлы күрсәткечләр белән таныштырып. Авырткан урыннарны да игътибарсыз калдырмады: – Сөткә бәяләрнең шактый төшүе шәхси ярдәмче хуҗалыклар икътисадына йогынты ясамый калмады, гомуми мөгезле эре терлекләр саны – 25 процентка, сыерлар саны 266га кимеде. 2022 елда 1 литр сөтне 30 сумнан тапшырсалар, 2023 елда уртача еллык сату бәясе 23 сумнан артмады.

Бу җәһәттән залдагы җирлек башлыкларына, авыл хуҗалыгы идарәсенә халыкка дәүләт ярдәме, уңышлы эшләп килүче хуҗалыклар турындагы мәгълүматны даими җиткереп торырга кушты район башлыгы.

Барлык тармакларны, күрсәткечләрне санап бетереп булмаса да, Арчадагы сәнәгатькә тукталыйк. 2023 елда райондагы киптерү цехында ремонт булган, әзер продукциянең өлгертү һәм капларга тутыру склады төзелгән.

Хәзерге вакытта чистарту корылмаларында масштаблы төзү эшләре башланган. Сәнәгать продукциясе җитештерү буенча алдынгы булу гына түгел, яңа эш урыннары булдыру максатыннан да эшләнә бу эшләр.

Узган ел Арчага килгән кунаклар саны да ике тапкыр диярлек арткан. Әллә никадәр сәнгать әһелләренең туган ягы булган Арчаның узган ел «Татарстанның мәдәни башкаласы» дип танылуы да очраклы хәл түгел.

– Әлеге конкурс кысасында мәдәни байлыгыбызны күрсәтеп, җиңү яулау – үзе бер кабатланмас тәҗрибә, горурлык, зур җаваплылык. Күп еллар дәвамында җуелган кыйммәтләрне бер ел эчендә генә кайтарып бетереп булмас, ләкин Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгышын әнә шулай, уенын-чынын бергә кушып башлады. Ләкин, җитешсезлекләргә күчкәнче, районның республика үсешенә керткән өлешен билгеләп үтте, аның тырыш халкын мактады. Авылда яшәүчеләрнең санын арттыру өчен барын да эшләргә кирәклеген, авыл кешесенең бик кадерле булуын әйтте.

– Тамак туйдыру җәһәтеннән әйтмим. Әйе, безне азык-төлек белән башлыча авыл халкы тәэмин итә. Шул ук вакытта милли традицияләр, тел, гореф-гадәтләр дә нәкъ менә авылда саклана, – диде ул. – Элек тә шулай иде, хәзер дә. «Улым, Казанга барсаң, укырга керсәң, зинһар, кайта күрмә», – дип озаталар иде, шулай бит? Авылда яшәү җиңел түгелдер, ләкин заманалар үзгәрә. Хәзер авылда да шәһәрчә яшәп була. Торак та, юллар да яхшы. Авыл күзгә күренеп үзгәрә, мөмкинлекләр арта.

Шактый күрсәткечләр буенча Арчада үсеш сизелсә дә, Фәрит Мөхәммәтшин сүзләреннән аңлашылганча, үстерәсе өлкәләр бар әле. Әйтик, халыкнын кереме буенча Арча республикада 40 нчы урында гына. Парламент Рәисе сүзләре белән әйтсәк, хезмәт хакын күтәрмәсәң, халыкны авыл җирендә калдырып булмаячак.

Фәрит Мөхәммәтшин районда юл һәлакәтләренең күп булуына, аларда үлем-китем очраклары теркәлүенә дә басым ясады. Җаваплы кешеләргә бу мәсьәләгә аеруча игътибарлы булырга кушты.

Кыскасы, эшлисе эшләр, ирешәсе үрләр бар. Ә Арчаның моңа буе җитмәслек түгел.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Арча – саннарда:

- Районда барлыгы **50166** кеше яши;
- 2023 елда **518** бала дөньяга килгән, **602** кеше үлгән;
- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләр – **16** эре авыл хуҗалыгы предприятиесе, 60 крестьян (фермер) хуҗалыгы, **10** авыл хуҗалыгы куллану кооперативы;
- 2023 елда Арча басуларыннан **160 мең** тонна ашлык җыеп алынган, сөт җитештерү **75 мең** тоннаны тәшкил иткән;
- сәнәгать җитештерүе индексы буенча Арча – республикада **3** урында;
- уртача хезмәт хакы – **42178** сум.

PHYGITAL ИГРЫ БУДУЩЕГО КАЗАНЬ 2024

Уеннар турында уйлар

«Киләчәк уеннары» халыкара чарасын спортчылар һәм оештыручылар гына түгел, халык та дулкынланып көтә. Барысы да яңача, моңарчы күрелмәгәнчә бит. Бу ярышлардан халык ни көтә? Ул республикага нәрсә бирә?

Ринат ГАЛИӘХМӘТОВ, блогер:
– «Киләчәк уеннары»на кадәр Казанда үткәрелгән сынау ярышларына йөрдем, машина узышында катнаштым, бокска бардым. Бу сынау ярышларына ничек әзерләнгәннәрен, ничек итеп тырышканнарын, аны ничек оештырганнарын үз күзләрем белән күрдем. Андый ярышларны да шундый ук югары дәрәҗәдә оештырганны, төп Уеннарның дәрәҗәсе ким булмас дип өметләнәм.

Мондый чара республиканы, әлбәттә, тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрәчәк. Бу – дөньядагы беренче шундый форматтагы Уеннар. Алар спортчыларны физик һәм акыл ягыннан ачачак, ике дөнья – виртуаль һәм чынбарлык бергә кушылачак. Мин бу чаралардан читтә калмаячакмын, әлбәттә, күзәтәчәкмен.

Лилия ЗӘЙНУЛЛИНА, ике бала әнисе:
– «Киләчәк уеннары»н түземсезлек белән көтәбез. Билетны алдан ук хәл итеп куйдык, төрле ярышларга сатып алдык. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән уеннар Казанда уза! Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярыймы инде?!

Олы улым футбол белән шөгыльләнә. Шуңа күрә иң беренче эш итеп фиджитал-футбол уены финалына билет сатып алдык. Бәясе дә кыйммәт түгел – 400–500 сум. Әле танылган футболчылар, артистлар да киләчәк, ди бит. Улыбыз бутсыларын алардан автографлар алу өчен күптән әзерләп куйды инде. Бик тә көтә. Балаларга, яшьләргә чын бәйрәм булачак бу, кыскасы. Роботлар һәм танклар ярышына да барачакбыз әле.

Максим ПЕСТУШКО, Уеннарның катнашучысы, хоккейчы:
– Тамашачыларның спортның гадәти төрләренә кызыксынуы, кызганыч, «яшәрми». Нәкъ тә шушы фиджитал формат яшьләрнең спортның барлык төрләренә кызыксынуын арттырыр дип уйлыйм. Бәлки, урыннан торып, шөгыльләнергә этәргеч булыр. Бу – искиткеч чара.

Фиджитал-хоккей димәктән, инде ничә ай тренировкаларга йөрдек. Бозда да, кибермохиттә дә әзерләнәбез. Команданы киберспортчылар һәм йә гамәлдәге, йә хоккейчы карьерасын туктаткан спортчылар тәшкил итә. Безгә ике юнәлештә дә профессионаллар булу мөһим. Киберспортчылар безне, без аларны нәрсәгә дә булса өйрәттек. Уеннар бик мавыктыргыч булачак.

Бозда ярыш нинди булыр дисезме? Шунысын әйтә алам: көрәш бик кискен булачак. Берәү дә җиңелергә теләми.

Александр ЕРМОЛАЕВ, Frame Tamer тәхәллүсе белән билгеле блогер:
– Бу юнәлеш үсәр һәм дөньякүләм кызыксыну табар дип саныйм. Виртуаль дөньяның һәм чынбарлыкның кушылуы шулай ук ошый. Без яңа юнәлешнең башында торабыз. Геймерларны чын спортчыларга тиңләячәкләр. Бу да яхшы. Минемчә, әлегә мондый форматтагы уеннарның булганы юк иде. Бу ниндидер киләчәк турында фильмны хәтерләтә. Уеннарның аналогы юк. Аның Россиядә башлангыч алуы бик тә яхшы.

Иван РЫБЧИК, Уеннарның катнашучысы, хоккейчы:
– Иң элек Казанга рәхмәт әйтәсе килә. Искиткеч оештыру, искиткеч кунакчыллык! Барысы да бик югары дәрәҗәдә. Командабыздагылар да, башка спортчылар да шундый фикердә. Сүз уңаеннан, безнең командабыз да – күпмилләтле. Турнир ярышларын, тамашачылар кебек үк, түземсезлек белән көттек.

ТАТАРСТАН — КАЗАНЫШ ҖИРЕ

ӘЙТКӘННЕ ҮТИСЕ

«ВОЛГА» ЭКСПЕРТЛАР КЛУБЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫНДА СОЦИАЛЬ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Борчыган мәсьәлә

Вәгъдә – иман. Иртәгә кояш чыкмаса да, социаль пособиеләр барыбер түләнәчәк. Ил-көндәге катлаулы хәлләргә карамастан, Хөкүмәт халык алдындагы бурычларын җиренә җиткереп үтәячәк. «Волга» экспертлар клубының чираттагы утырышында яңгыраган төп фикер әнә шуннан гыйбарәт.

Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева дәүләт бүген үз өстенә алган барлык социаль бурычларны тулысынча үти дигән фикердә. Нәтиҗәсе саннарда күренә. Бу урында Ләйлә Фазлыева республикада гомер озынлыгы арту, төрле мәкерле чирләрдән үлүчеләр саны кимүне телгә алды.

– Хәзер халык дәүләттән күбрәкне өмет итә. Көтәләр икән, димәк, ышаналар, – ди вице-премьер. – Бүген республикада инфраструктура үзгәрешләре дәвам итә, мәктәп һәм балалар бакчалары, мәдәният оешмалары төзелә, төзекләндерелә. Районнарда китапханәләр, клублар ачыла. «Парк һәм скверлар» программасы да халыкта зур кызыксыну уятты.

Кызыксыну димәктән, Татарстанда яшәүчеләр илдәге, республикадагы үзгәрешләр белән даими кызыксынып тора икән. «Диалог Регионы» оешмасы уздырган тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Оешманың Татарстандагы бүлеге җитәкчесе Марсель Гыйльмеев сүзләренә караганда, тикшеренү барышында халыкның 66 проценты республикада күрсәтелгән медицина ярдәменә яхшы бәя биргән.

> Иң беренче чиратта, халык Татарстанда югары технологияле операцияләр ясалудан, медицина оешмаларының заманча җиһазлар белән тулылануы, яңартылуыннан канәгать. Монда ФАПлар төзелеше дә кергән. Халык медицина хезмәткәрләренең даими рәвештә белемнәрен арттырып торуыннан да канәгать. Республика халкы Россия Президенты Владимир Путин гамәлгә керткән «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты турында да белә. Татарстандагы уңай үзгәрешләрнең нәкъ менә шушы проектка бәйле булуыннан да хәбәрдар алар, – диде Марсель Гыйльмеев.

Социаль бурычлар исә халыкны иң кызыксындырган мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов социаль бурычларның Конституциядә урын алуын искәртте.

– Ел саен бюджет караганда Дәүләт Думасы төп сумманы социаль бурычларны үтәүгә калдыра. Аның күләме кимеми, ул ел саен индексацияләнә. Илкүләм муллык фонды хисабынамы, кредитлар хисабынамы – ни генә булса да, ул барыбер түләнә. Иртәгә кояш чыкмаса да, социаль пособиеләр барыбер биреләчәк, – ди депутат.

Социаль бурычлар дигәндә, Айрат Фәррахов, иң беренче чиратта, пенсия, хезмәт хакы, бушлай дәвалану һәм белем бирүне күздә тота. Депутат кадрлар мәсьәләсенә дә кагылды. Дәүләт Думасы депутаты фикеренчә, Мәскәү белән Казанда яшәүчеләр генә түгел, авыл халкы да сыйфатлы медицина ярдәме алып яшәргә тиеш. Сүз уңаеннан, Россия Президенты Владимир Путин быелның 1 мартыннан кечкенә шәһәр һәм авыл җирлекләрендә эшләүче медицина хезмәткәрләренә түләнә торган өстәмә акчаны 50 мең сумга кадәр арттырырга тәкъдим итте.

> Бүген Россия үзенең суверенитетын яклый, шуңа күрә оборонага дигән чыгымнарны да арттырырга мәҗбүр. Әмма күреп торабыз: икътисадыбыз бүгенге катлаулы сәяси шартларда да үсүен дәвам итә. Тиздән без алдагы өч елга бюджет формалаштыра башлаячакбыз. Анда иң беренче чиратта социаль чыгымнар билгеләнәчәк. Оборонага планлаштырылган чыгымнар исә шуннан соң гына салыначак, – дип ачыклык кертте Айрат Фәррахов.

Фәрраховның бу сүзләре белән Россия Дәүләт Думасы депутаты Максим Топилин да килеште. Дәүләтнең халык алдындагы социаль бурычларын тулысынча үтәп кенә калмыйча, узган ел илдә уртача хезмәт хакының 7 процентка артуын да искәртте ул.

– Без элегрәк хезмәт хакы буенча Европа илләреннән калыша идек. Вакыт узу, икътисад үсү, хезмәт җитештерүчәнлеге арту белән бар да үзгәрә. Бу күренешләр алга таба да дәвам итәчәк, – дип ышандырды депутат.

Булганның кадерен аны югалткач яки башкалар белән чагыштырганда гына аңлый башлыйсың. «Волга» экспертлар клубы утырышында катнашучылар да, сүзләренең хаклыгына тагын да инандырырга теләп булса кирәк, үткәннәрне искә алды.

Максим Топилин 1998 елгы кризистан соң бар нәрсәне яңабаштан башларга, шуңа өстәп әле халыкның ышанычын яңадан яуларга туры килүен дә искә төшерде. Шуңа күрә социаль бурычларны акрынлап арттыру аякта басып калырга ярдәм итәчәк, дип саный депутат.

Айрат Фәррахов та ул еллардагы тәҗрибәсен искә алды.

– 1995 елда мин – кызыл дипломлы белгеч – РКБга эшкә килдем. Айлар буе хезмәт хакы алмаган чаклар күп булды, дарулар булмауны әйткән дә юк. Шундый бер очрак истә калган. Хастаханәдән чыгу юлында Түбән Камадан килгән йөк машинасы тора иде, анда көпчәкләр төялгән. Табибларга хезмәт хакы түләү өчен аларны берәр нәрсәгә алыштырырга туры килде. Хөкүмәтнең планы да, акчасы да юк иде. 2000 елдан башлап кына хезмәт хаклары түләнә башлады, илкүләм проектлар, җиһазлар пәйда булды, – ди депутат.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯШЬЛЕК ПОЕЗДЫ

ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ МӘСКӘҮДӘГЕ «РОССИЯ» КҮРГӘЗМӘСЕН КАРАП КАЙТТЫ



minmol.tatarstan.ru

Сәяхәт

Яшь галимнәр, эшче яшьләр, волонтерлар, табиблар, яшь гаиләләр, активистлар, КВН уйнаучылар, блогерлар – барысы да бер поездда. Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының «Яшь юлчы» проекты кысасында 500 кеше Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) оештырылган «Россия» күргәзмә-форумына барып кайтты. Алар арасында «ВТ» хәбәрчесе дә бар иде.

– Бу күргәзмәне бөтен кеше үз күзе белән күрергә тиеш. Чөнки ул илебезнең байлыгын күрсәтә. Республикабыз өчен аеруча горурлык хисе туа, – дип тәэсирләре белән уртаклашты «Ел студенты – 2023» Гүзәл Газетдинова. – Иң истә калганы – Яшьләр йортында очрашу. Анда мин Россия Герое Дамир Йосыповка сорау бирдем. «Яшьлегегезнең безнең көннәрдә үтүен теләр идегезме?» – дип сорадым. Аның җавабы бик кыска булды: «Яшьлегемне бернәрсәгә дә алмаштырмас идем», – диде. «Яшь юлдаш» кебек проектлар күбрәк булсын иде. Күренекле шәхесләр белән очрашу, тәҗрибә туплау – үсәр өчен зур этәргеч ул.

Яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Сабирова сүзләренчә, «Яшь юлдаш» проектында катнашырга 1000нән артык кеше гариза җибәргән, шуларның яртысына әлеге сәфәрдә булу бәхете елмайган.

Фән алдынгылары

Форум-күргәзмә кысасында Фән һәм университетлар көне узды. Очраклы гына түгел. Бу елның үзенчәлеге – фән һәм технологияләр унъеллыгының дәвам итүе, Россия Фәннәр академиясенең 300 еллыгы һәм Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы. Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов әнә шуны искәртте.

Сүз уңаеннан, яшь галимнәр саны буенча Татарстан – илдә алдынгы. Россиядә яшь галимнәр 40 процент булса, бездә – 60. Фәннәр академиясе президенты әнә шундый саннар белән дә сөендерде.

– Илнең башка төбәкләре белән чагыштырганда, бездә яшь галимнәр күбрәк. Әле тынычланмыйбыз, бүген аспирантура юнәлешенә басым ясыйбыз, – дип билгеләп узды Рифкать Миңнеханов. – 50 инженер мәктәбенең бишесе – Татарстанныкы. Технологик эшмәкәрлеккә килгәндә, 442 җиңүче стартап бар, без аларны миллионерлар дип атыйбыз. Нигез бар. Быел нигезебезне сакларга, көчәйтергә һәм нәтиҗәгә ирешергә кирәк.

«Кайда авыр – сез шунда»

Бу көнне күргәзмә-форумда Россия Студентлар отрядлары көнен һәм студентлар отрядлары хәрәкәтенең 65 еллыгын да зурлап билгеләп үттеләр. Илнең иң яхшы студент отрядларын бүләкләделәр. Безнекеләр монда да сынатмады. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы югары уку йортлары арасында иң яхшысы дип Казан дәүләт аграр университеты табылды. Аларны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Татьяна Голикова бүләкләде.

– Соңгы 20 елда Россия студентлар отрядларына 6,5 миллионга якын яшь кеше кергән. Бу – бик җитди сан. Димәк, Россия студентлар отряды хәрәкәте үсә һәм алга бара. Кайда авыр һәм зур тырышлык таләп ителә – сез шунда. Эшләгән эшегез өчен бик зур рәхмәт сезгә, – дип мөрәҗәгать итте ул җиңүчеләргә.

Министрдан җылы сүз

Талантлы, ярдәмчел, аңлаучан, зирәк. Татарстан яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков Мәскәүдә республика яшьләрен мактап туя алмады.

– Бүген Татарстан яшьләре өчен мөһим көн. 500 кеше Халык хуҗалыгы казанышлары белән танышты. Республикада һәм яшьләр сәясәтендә иң мөһиме – яшьләр. Безнең яшьләр бик талантлы, һәрвакыт ярдәмчел һәм аңлаучан. Иң мөһиме – алар зирәк! Аларга бу сыйфат әби-бабаларыннан күчкән, – диде ул.

Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Эмиль Фәйзуллин да якташларын сәламләде.

– Рөстәм Миңнеханов ел дәвамында Мәскәүдә якынча 60 көн уздыра, 15–20ләп очрашу һәм чарада катнаша. Республика җитәкчелегенең мондый активлыгы безне шундый ук булырга һәм башка төбәк вәкилләре арасында аерылып торырга мәҗбүр итә, – диде Эмиль Фәйзуллин. – Мәскәүдәге татар яшьләре белән һәрвакыт элемтәдә торабыз. Югары уку йортларында Татарстан якташлыклары эшли. Мәскәүдәге һәр университетта 500дән артык Татарстан яшьләре укый.

Сезне анда кем көтә?

«Яшь юлчы» проекты кысасында Татарстан яшьләре өчен бай программа әзерләнгән иде. Иң әһәмиятлеләренең берсе – Россия Геройлары Рәсим Баксиков һәм Дамир Йосыпов белән очрашу.

– Берничә ел элек яшьләр белән сөйләшкәндә: «Без чит илгә китәргә телибез. Бу илдә нишләргә?» – диләр иде. Мин алардан: «Сезне анда кем көтә? Сез анда чит кешеләр, анда сез башка дәүләткә, башка илгә файда китерәсез. Ә туган илегез өчен берәр нәрсә эшләдегезме?» – дип сорадым. «Бездә начар», – дип әйтү җиңел. Ләкин яхшы булсын өчен сез нәрсә эшләдегез? Бу турыда һәркем уйлансын иде, – диде Дамир Йосыпов.

Ләйсән САФИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

БАДАМШИН ШАМИЛ СӘГЫЙТ УЛЫ

(21.11.1939 – 16.02.2024)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясенең элекке җитәкчесе Бадамшин Шамил Сәгыйт улы 16 февральдә 85 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Шамил Бадамшин 1939 елның 21 ноябрендә Архангельск өлкәсенең Котлас шәһәрендә туган. Ангрен тау техникумын тәмамлаганнан соң хезмәт эшчәнлеген «Узбекшахстрой» төзелеш идарәсендә арматурачы сыйфатында башлап җибәргән. 1961 елда Казанга күченгәч, трамвай паркында слесарь булып эшләгән.

Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, 1965 елда Казан финанс-икътисад институтына укырга кергән. Икенче курста укыганда Казахстан ССРга чирәм җирләрне күтәрергә киткән.

Шамил Сәгыйт улы 1969–1990 елларда ТАССР Финанс министрлыгында төрле вазыйфалар биләде: өлкән ревизордан алып ТАССР финанс министры урынбасарына кадәр хезмәт юлы узды.

1990 елда аңа ТАССР Финанс министрлыгында булдырылган Дәүләт салым инспекциясенә җитәкчелек итү һәм аның эшен җайга салу бурычы ышанып тапшырылды. Бу оешма 1992 елда Татарстан Республикасында Дәүләт салым инспекциясе итеп үзгәртелде.

1998–2010 елларда ул Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе булды. Әлеге вазыйфада халыкның дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә эшләвен тәэмин итте, законнар һәм норматив актларны камилләштерү йөзеннән күпне эшләде, иң катлаулы проблемаларны хәл кылу юлларын тапты.

Шамил Бадамшинның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре, «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» мактаулы исеме, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты.

Шамил Сәгыйт улы чын профессионал булу белән беррәттән, күренекле шәхес тә иде. Куелган максатына ирешүдәге ныклыгы, эшенә, идеалларына тугрылыгы, шулай ук кешеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәте аңа коллегалары арасында һәм җәмәгатьчелектә зур абруй-хөрмәт китерде.

Бадамшин Шамил Сәгыйт улының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.М. СИТДИКОВ, Р.Р. ГАЙЗАТУЛЛИН, И.Р. МЕТШИН, М.Ә. САФИУЛЛИН, Х.Г. ИШТИРӘКОВ, И.В. ТЕРЕНТЬЕВА

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, әнисе

СЕРГЕЕВА Зоя Афанасьевнаның

кинәт вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү бүлеге 1 разрядлы өлкән белгече Сергеев Валерий Львовичның авыр кайгысын уртаклаша. Бу авыр көннәрдә сабырлык бирсен.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Тимер юл вокзаллары дирекциясе Горький тимер юл вокзаллары төбәк дирекциясенең Әгерҗе тимер юл вокзалы җитәкчесе **Бареков** Евгений Владимирович Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы хакимияте башлыгы **Козлов** Вячеслав Михайлович Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмати технологияләр, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе җитәкчесе **Огородников** Алексей Игоревич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Бавлы-нефть» нефть-газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Салихов** Илдар Ленарис улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге зур хезмәтләре өчен **Нуралиева** Алия Фаил кызы, **Мотыйгуллин** Илнур Равил улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Агросила» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Ситдиков** Дилшат Галимҗан улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Түрә галимне җиңсә...

Язманы башлаганда янә дә данлыклы милләттәшебез, Россия Фәннәр академиясе академигы Роберт Нигъмәтуллинга мөрәҗәгать итәсе килә. Узган ел Орел шәһәрендә узган халыкара форумда ул: «Киләсе 10–15 елда илдә җитештерү өлкәсе белгечләре – токарь, слесарь, фрезеровщик кебек эшчеләргә коточкыч кытлык булачак», – дигән иде. Кытлык инде бүген үк яхшы сизелә. Тик бу хәл – мәсьәләнең әле бер ягы гына.

Бер Нигъмәтуллин гына түгел, төрле өлкәләргә караган исеме билгеле галимнәр соңгы елларда чаң кагып килә. Фән аксакаллары илнең тирән системалы кризиста булуын белдерә. Алар әйтүенчә, бу кризиска без, елан авызына керәчәк гипнозланган куян кебек, үңга-сулга тайпылмыйча, 15–20 ел буе килдек. Бүгенге кризис тормышның бөтен якларына диярлек кагыла. Икътисадка да, социаль өлкәгә, медицинага, белем бирү системасына, хәтта эчке һәм тышкы сәясәткә дә. Хәтта мәдәният өлкәсе дә, «базар барысын да үзе көйли» принцибына ышанып, башы-аягы белән базар мөнәсәбәтләренә тапшырылган. Фән турында әйткән да юк. Фән белән белем системасы – илнең иртәгәсе. Тик моны аңларга теләүчеләр аз.

Илгә бүген яңа модернизация кирәклеге ачык. Бу – ни дигән сүз? Бу халык хуҗалыгының барлык тармакларын да заман таләпләренә җавап бирер дәрәҗәгә җиткерүне аңлата. Беренче чиратта җитештерү өлкәсен. Үзебездә җитештерелгән товар, җиһазлар исемлеге артырга тиеш. Халыкара кооперация, халыкара хезмәт бүленеше – әлбәттә, шәп нәрсә. Тик менә «тышкы сәясәтнең дөрес түгел» дип сине санкцияләр белән чикләгәндә нишләргә? Монысы – бер яктан. Икенче яктан, син банан республикасы түгелсең икән, алай гынамы, үзеңне лаеклы һәм бөек илгә санаысың икән, шул ук авиалайнерларны җитештермә хәлең юк. Станокларны, электрониканы да. Боларны аңлау моңа чаклы булмады. Нефть долларлары яңгыры, җиңел килгән акча безне ваемсыз итте генә түгел, купмедер дәрәҗәдә акылыбызны да алмады микән? Имеш, акчага бар нәрсәне дә сатып алып була. Була иде, хәзер менә юк. Булганда да фәнне, сәнгатьне үстермичә, табигый байлыклар саткан акчага карап тору – булдыксызлар гамәле бит. Тик бездәге чиновниклар өчен, аларның власте нығысын, какшамасын өчен, бу кулай. Аларга фикерле кешедән бигрәк кредитларга чумган кулланучылар армиясе, очсызлы хезмәт базары кирәк.

Җитештерү тиешенчә эшләп китсен өчен, инвестицияләр, ягъни максатчан акча һәм фәнгә аерым, хәтта гадәттән тыш игътибар зарурлыгы ачык. Чөнки бары даими, перманент фәнни алгарыш кына заманча технологияләр биреп торырга сәләтле. Технологияләр тудырмыйсың икән, шул ук банан республикаларыннан син ни дәрәҗәдә аерыласың соң?..

Системалы кризис, дигәндә әле тагын да бер бәла бар. «Непрофессионализм» сүзен татарчага үз шөгылеңдә сай йөзү, аңа тәңгәл килмәү, дип тәрҗемә итеп буладыр. «Дилетантлык» дигән төшенчә дә шул сыйфатны аңлата. Соңгы ике дистә елда шул затсызлык гөрләп чәчәк атмыймы бездә, дип сорыйсы килә. Ата. Аның метастазларын барлык өлкәләрдә табарга мөмкин. Тоташ дилетантлык каян чыга соң? Белгечләр монысына да җавап бирә. Иң югарыдагы башлыклар да кул астында эшләүчеләрне күбесенчә һөнәрилегенә, гыйлеменә, булдыклылыгына карап түгел, ә үзенә лояльлегенә, һәрчак «ярар» дия белүенә карап сайлый. Үз фикере булган, җитәкче белән килешмәгән, матур итеп койрык болгый белмәгәннәр читтә кала. Ишерен-батырын түгел, Россиядә бу – эпидемия рәвешен алган кимчелек, менталитет. Мондый хәл системалы кризис тудырурга ничек үз өлешен кертмәсен! Нәтиҗә исә гафу итәлмәслек – биләмәләре тагыйбый байлыклар белән тулы ил тормыш сыйфаты рейтингларында җиденче дистәдә бутала. Шундый хәлләрдән соң кыш галимнәр чит илләргә китә, шунда төпләнә, килочәкне шунда күрәләр, дип гаепләргә хакыбыз бар микән безнең?

«Непрофессионализм» төрле дәрәҗәдәге җитәкче, чиновникларның үзләренә дә бик кагыла. Бездә шундый гадәт: югары кәнәфигә ирешкән кешегә карыйлар да: «Шулкадәр өскә күтәрелгән, бик акыллыдыр инде бу», – диләр. Һәм ялгышалар. Бик алай түгел шул. Акыллыдан бигрәк елгыр, шомалар кунаклый кәнәфигә. Ә бит социаль лифтлар, әгәр дә ки алар төзек һәм камил икән, барыннан да бигрәк гыйлеме, сәләте, акыллы булганнарны өскә күтәрергә тиеш. Кода-кодагыйларны, ярый белгәннәрне, лояльләрне түгел. Әйе, «баш өсте» дип торганнар, сүзсез буйсынганнар белән эшләү җиңел. Ә чын сәләтнең исә күп мәсьәләдә үз фикере, алар белән авыррак. Башлык шуның өчен дә башлык, ул алар белән дә уртак тел табып, бер фикергә килеп, кирәк икән, үз фикереннән чигенеп тә эшли белергә тиеш. Объективлык, ул китергән алгарыш шул чакта гына мөмкин. Бу булмаган оешмамы ул, олы корпорацияме, илме, озак еллар бер кеше акыллы белән генә яши икән, уңыш көтмә.

Алдынгы җәмгыятьләрдә фәннең сәясәттән өстен торуы, сәясәт фәнне түгел, фәннең сәясәтне билгеләве мәгълүм. Бигрәк тә икътисадый сәясәтне. Ил җитәкчеләренең дә галимнәр белән даими диалогта торырга, олигархлардан бигрәк аларны тыңларга, шулар белән киңәш-табыш итәргә тиешлеге бик ачык. Ил дөньядан артта калмасын дигәндә, шул ук академикның югары чиновниклар бер башка югарырак бәяләнүе мөһим. Түрә министр кәнәфиендә утырган җәһәттә дә. Ул гынамы, зурдан алганда, кеше затының күпме эшләргә, күпме ял итәргә, ничә яшьтә пенсиягә чыгарга, күпме пенсия алырга тиешлеге дә фән аша, фәнни анализга нигезләнеп билгеләнергә тиеш. Чиновник теләгәнчә түгел.

«Әләктереп» алырга да күп сорамый

Безнекеләр

«Ватаным Татарстан»ны кулга алдыгызмы? Хәзер инде, укый башлаганчы, һәр битен әйләндереп карап чыгасыздыр? Язмалар ничек куелган? Фотоларның сыйфаты ничек? Сызыклар, бизәкләр, рубрикалар, баш исемнәр... Кыскасы, һәрберсе күңелегезгә хуш килеп тора, әйеме? Бу – дизайнерлар эше.

Бүген бездә бәйрәм. Шушы һөнәр иярләренең берсе Марат Хәбибуллинга – 50 яшь. Компьютерлар бүлмәсенә керү белән, һәр кеше сөйләшүне көтлаудан, матур-матур теләкләр теләүдән башлый. Мин исә, шуе бик тыгыз булса да, Марат белән сөйләшеп алу бәхетенә дә ирештем.

Анна Арахамия

Үзем дә сизми калдым

Марат үзенең сабырлыгы, тыйнаклыгы белән җәлеп итә. Әммә, әйтергә кирәк, эшне җиренә җиткереп эшләмәсәң (текст каталы булса, фото вакытында тәгаенләнмәсә), «әләктереп» алырга да күп сорамый. Тәртип ярата ул. Үзе дә шундый, башкалардан да шуны таләп итә. Юкка гына түгел бит инде. Ахыр чиктә «Ватаным» әйбәт чыксын өчен тырыша. Марат өчен бу газета да, коллектив та бик кадерле. «Барысы да туганнар кебек», – ди ул хезмәттәшләре турында. Шулай килеп чыккан, бәлки бу очраклы түгелдер, бәлки алай түгелдер, ул шушы көнгә кадәр хезмәт юлын «Ватаным Татарстан»да үткән. Мәктәпне тәмамлагач та, Казан энергетика институтына укыган. Пермь крайындагы Чайковский шәһәрендә армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, үзе дә көтмәгәндә, редакциягә эшкә килгән. «Ничек шулай килеп чыкты?» – дигән сорауга Марат болай җавап бирде:

– Үзем дә аңламый калдым. Беркөнне шулай Марат Гыйләҗев (бу Марат бездә компьютерлар цехы җитәкчесе. – **Ред.**) очрады. Эшкә урнашырга өлгермәгән идем әле. «Әйдә, безгә кил», – диде. Элек компьютерлар бик сирәк иде бит. Кызыксынып кына барган идем.

Тора-бара газетаны дизайнлауның чын иҗат эше икәнлегенә төшендем. Көн артыннан көн үтә торгач, шул дөньяга кереп китүемне сизми дә калдым.

Иҗатчылар гаиләсе

Иҗат эше дигәннән, Маратның болай сөйләнүенә бер дә гаҗәпләнәсе юк. Ул иҗатчылар, зыялылар гаиләсендә чын татар егете булып үскән. Әтисе Сәгыйть Хәбибуллин – профессор. 83 яшендә бүген дә Казан консерваториясендә студентларга белем бирә. Әнисе Мөнирә Хәбибуллина – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать хезмәткәре. Радио комитетында концертмейстер булып эшләгән. Пианинода уйнаган, җырлар да язган, үзешчән композитор. Хәзер лаеклы ялда. Энекәше Ринат та әтиәнисе эзеннән киткән. Музыка мәктәбендә укыганнан соң музыка училищесында, консерваториядә белем алган. Үзе укыган училищеда белем бирген. Хәзер Төркиядә яши. Марат та кимен куймаган. Музыка мәктәбен тәмамлаган, фортепианода уйнарга өйрәнгән, хорда җырлаган.

– Ул вакытта ничектер җиңелрәк иде. Куркыныч түгел иде бит. Трамвайга утыра идем дә гел үзем йөри идем. Энекәшем дә шулай булды. Әти-әнигә йөк булмадык. Алар иркенләп үз эшләре белән шөгыльләнделәр, – ди Марат, ул вакытларны искә төшереп.

Юбилеең белән котлыйбыз, Марат. Исән-сау булып, һәр көнгә шатланып яшәргә язсын. Иҗади уңышлар телибез сиңа. Бу газета өчен дә, коллектив өчен дә, укучыларыбыз өчен дә бик кирәк.

Шахмат мәктәбенә дә йөрергә өлгергән әле ул. Беренче разрядлы спортчы булган.

Хәбибуллиннар гаиләсендәге иҗат кешеләре исемлеге моның белән генә тәмамланмый. Аның әнисе ягыннан бабасы – үлемсез шигырьләр авторы Мөнир Мазунов. Заманында Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров кебек күренекле композиторлар белән иҗат иткән талантлы шагыйрьнең җырлары хәзер дә яңгырый.

Мөнир Мазунов Пенза өлкәсенең Карлыган авылында туып-үскән. Беркавым ничектер андагы туганнар белән элемтә өзелеп киткән. Бабасы бакыйлыкка күчкәндә Маратка 12 яшь кенә булган әле.

Моннан җиде ел элек ул социаль челтәрләр аша өч туган апасы белән табышкан. «Хәзер инде элемтәдәбез. Югалырлык түгел», – ди Марат. Бу аңлаклыкны буыннан-буынга күчереп калдыруны да хуп күрә: улы Кәрим белән барысын да урталаша.

Казанда туып-үссә дә, Марат татар телендә искиткеч яхшы сөйләшә. Бөтен нечкәлекләрен белә. Хәер, «Ватаным»да башкача мөмкин дә түгел. Кайчакларда безнең дә хаталарны төзәтеп, бик кыйммәтле киңәшләрен әйтеп җибәрә әле ул. Туган телне белүен әби-бабай тәрбиясе дип саный.

– Мин өч яшькә кадәр әтием ягыннан Фатыйма әбием белән үстем. Русча бөтенләй белмәгәнмен. Аннан инде җәйләрне Мөнир бабай бакчасында, аның янәшәсендә үткәрдем. Сөйләшүләр дә, тәрбия дә татарча иде. Бер дә онытылырлык булмады, – дип шаян гына җавап бирә Марат бу җәһәттән.

Хезмәттәшебез белән газетаның бүгенге хәле турында да иркенләп сөйләшергә иде исәп. Әммә ул, эшлисе бар дип, сүзне кыска тотты:

> «Ватаным Татарстан» профессиональ дәрәҗәдә чыга торган газета дип уйлыйм. «Әгәр (кемдер) берәр нәрсә үз эшен эшли икән, аңа кирәкмәгәнгә тиюдән мәгънә юк» дигән гыйбарә бар. Мин шуңа таянам. Һиндидер зур үзгәрешләр кертергә вакыт җиткән икән, ул үзеннән-үзе билгеле була. Әлбәттә инде, торгынлыкка төшмәскә, көн дә һәрьяктан уйлап, дөрес итеп, заманадан калышмыйча эшләргә кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Нәтиҗә

ТЫЙНАК БӘЙРӘМ

Татарстан Язучылар берлегендә әдәби әсәрләр бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләделәр

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

– Язучы ул бала кебек: аңа матур итеп сүз әйтмәсәң, кирәк чакта башыннан сыйпап җибәрмәсәң, ул алла ни алга бара алмас, – ди Әлфис Гаязов.

Әдәби мәйданда иң зур, иң саллы һәм иң шау-шулы бәйге өметләрне аклаганмы? Быелгысына да нәтиҗә ясар вакыт җитте.

Бәйге җиңүчеләрен котларга Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов килгән иде.

– Мин бит сезне күбрәк дип уйлаган идем. Шундый матур бинага, матур тантанага зал тутырып киләсе дә бит. Тыйнаграк килеп чыккан, – дип, залның тулы булмавына гаҗәпләнүен яшермәде ул. – Ярый, элеккесе белән чагыштырганда, өстән янгыр явып тормый әле, – дип тә өстәде, уенын-чынын бергә кушып.

Марат Әхмәтов сүзләренчә, әлеге бәйге халкыбызның әдәби чишмәсенең мул сулы икәнлеген күрсәтә.

– Әдәби бәйге – безнең комиссиянең (Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе) иң беренче проекты. Республика Рәисе Рөстәм Нургали улы белән очрашып, беренче киңәш-табыш иткәндә ул аны хәтта үзе үк тәкъдим итте. Бездә талантлы язучылар, шагыйрьләр, каләм осталары бар икән. Меңнән артык килгән язма – каләм чарлана, осталык арта, мәйдан киңәя бара дигән сүз. Бүген укучы игътибарына бихисап күп язма тәкъдим ителә. Бу әсәрләр укучыны татар китабын укырга җәлеп итәр дип уйлыйм. Бәйге, һичшиксез, дәвамлы булырга тиеш, – диде ул.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла бәйге иҗат ялкынын дөрләтеп җибәрү өчен генә түгел, матди яктан да зур ярдәм булганын әйтте.

– Әлеге әдәби бәйге – зур дәрья кебек һәм аңа төрле сулар килеп кушыла. Аларның күпләре безне сөендерә, әлбәттә. Тик аларның төрлесе бар. Тирән сулы инешләр, сай сулы инешләр бар. «Нишләп минеке җиңмәде?» – дип шалтыратучылар бар. Быел Башкортстаннан да катнашучылар булды һәм мине гаҗәпләндергәне – башкорт язучылары да шактый катнашкан икән. Безнең тугандаш халык вәкилләре дә катнашкач, димәк, бу – дөрес бәйге. Һәм, ул чыннан да, безнең язучыларга стимул. Әлбәттә, бирүчегә күп, алучыга һәрвакыт аз тоела. Әммә мондый дәрәҗәдәге бәйгенең беркайчан да булганы юк иде әле. Моның өчен республика җитәкчелегенә һәм комиссия рәисенә рәхмәт.

Бер мичкә балга бер кашык деготь дигәндәй, Ркаил Зәйдулла аз гына тәнкыйть сүзләре дә ишеттерде:

> **– Марат Готыф улы өченче бәйге турында әйтте, димәк, әле язарга да язарга. Ләкин башта бик күп укырга кирәк. Чөнки, кызганыч, күбебез тапталган юлдан бара. Минемчә, дөнья әдәбияты белән танышу җитмидер. Европа, Шәрык, Кытай әдәбиятында нинди тенденцияләр – яңадан велосипед уйлап тапмас өчен дөнья әдәбиятын яхшы белергә кирәк.**

Яңа, узенчәлекле, «маймылы» булган әсәрләр язарга кирәк. «Маймылы» күз кысып торсын әсәрләрегезнең, диде ул язучыларга.

Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ бәйге әсәрләрен укыгач, жюриларның дөрес бәяләвен сизүен әйтте.

– Бу бәйге тирәсендә нинди генә сүз, упкәләүчеләр, көнләшүчеләр булса да, аның булуы – безнең әдәбият, мәдәният тарихында бик зур вакыйга. Бик күп өр-яңа талантлар ачылганын күреп һәм укып шатланам. Бу бәйгеләрдә җиңгән әсәрләр журналда, китапта басылгач, укымыйча калмыйм. Язучылар туа тора, әсәрләр языла тора. Хәзер безгә яңа буын укучыларны тәрбияләргә кирәк. Мәктәпләргә, югары уку йортларына җиткерергә кирәк. Безнең татар әдәбияты бар һәм, Тукай әйткәнчә, булачак, – дип сөйләде халык шагыйре.

«Романнар» номинациясендә беренче урын алган Башкортстан язучысы Әлфис Гаязов оештыручыларга рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Бүген бу бәйгенең әһәмияте турында күп әйттеләр. Әһәмияте зур гына түгел, ул бернинди кысаларга да сыймый. Мондый ярдәм булмаса, берлек эше дә, язучылар эше дә алга бармый. Мин язучыны бала белән чагыштырыр идем. Аңа матур итеп сүз әйтмәсәң, кирәк чакта башыннан сыйпап җибәрмәсәң, ул әлә ни алга бара алмас, – диде Әлфис Гаязов.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби исәпкә алучы хезмәткәре **Гарипова** Гөлнар Рәшит кызы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге башлыгы **Зыятдинов** Альмир Имаметдин улы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы **Насертдинов** Дамир Вагыйзь улы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге башлыгы **Павлов** Иван Алексеевич, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Умылина** Любовь Владимировна, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күәм авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Фәйзиева** Айгөл Габделфәт кызы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хисамова** Ләйсирә Абуләес кызы, Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Юнысова** Миләүшә Мәүлет кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Поносов** Эдуард Александрович; җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттырудагы казанышлары, Арча муниципаль районының финанс-икътисад өлкәсе үсешенә өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенең бюджет бүлеге башлыгы **Сабирова** Сирена Габделнур кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Биектау-Сервис» коммерциячел җитештерү төзелеш фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гыйбадуллин** Ренат Вилдан улы, «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» акционер җәмгыяте генераль директоры **Исаевич** Александр Игоревич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«КАЙМАК» ҖАВАПЛЫЛЫГЫ ЧИКЛӘНГӘН ҖӘМГЫЯТЕ ресторaны идарәчесе **Мотыйгуллина** Ирина Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ШАГЫЙРЬ ВАСЫЯТЕ

Үтеп барышлый

Биектау районы Алан-Бәксәр авылыннан Наил абый Кәлимуллинның редакциягә килеп чыгу сәбәбе герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көненә бәйле булып чыкты.

Ике атна

– Еллар үткән саен, үткәннәр турында күбрәк уйланасың, күбрәк эзләнәсең. Муса Җәлил турында күп язылган инде. Минем әтием Григорий да (мулла кушкан исеме Гәрәй) аның белән ике атна төрмәдә утырган. Күргәннәрен сөйләргә ярата иде ул. Әни генә: «Күп сөйлисең. Башыбызны төрмәгә тыкмасаң ярый инде», – дип сукрана иде. «Мәктәптә, урамда сөйләнеп йөрмәгез тагын. Әтиегезне төрмәгә утыртырлар», – дип, безне дә кат-кат кисәтте. Куркудандыр инде, күрәсең, балачакта әти сүзләренә артык игътибар да ителмәгән, истә калганнары бик аз, – дип, башта тыйнак кына моң-зарын сөйләп алды ул. Аннан истәлекләрен барларга кереште.

– Әсирлеккә эләгеп, бер карт немец хуҗалыгында эшләп йөргәндә, әтиемне төрмәгә утырталар. «Анда минем янга кара тутлы, матур гына бер кеше килеп сөйләшә башлады, – дип сөйли иде әтием. – Үзен Муса Җәлил дип таныштырды. Кайдан икәнлегемне сорады. Буа районының Адав-Толымбай авылыннан дигәч, авылыгызны беләм, сездән чыккан язучы да бар, диде. «Минем исән калуым икеле, мин – коммунист. Исән-сау котылсагыз, безне дә искә алыгыз, тормышның кадерен белегез. Мин дә белер идем», – дип кабатларга ярата иде.

> **Бик уйчан иде ул. Гел күзләрен берәр ноктага төбәп, ишекле-түрле йөрде дә йөрде. Кем белә, күңелендә шигырь юллары туган чак булгандыр. Бәлки, гаиләсе, кызы Чулпан, иле, халкы, иптәшләре турында уйлагандыр. Ә бәлки, әсирлектән котылса, киләчәк тормышын күз алдына китергәндер.**

Ике атналап вакыт үткәч, аны алып киттеләр. Безгә таба елмаеп борылган иде, күрәсең, саубуллашырга диптер инде, яңагына китереп суктылар. Шуннан соң мин аны күрмәдем. Безнең янга кайтармадылар».

Әтием шуларны да сөйләргә куркып яшәгән. Әмма Җәлил тормышын өйрәнүче белгечләр бу хакта белгәннәрдер, күрәсең. 1996 елда аны Казанга, герой-шагыйрьнең туган көнендә хатыны Әминә, кызы Чулпан

TASS

һәм оныгы белән очрашуга чакырдылар. Ураза вакытына туры килгән иде булса кирәк. «Кунаклар белән рәхәтләнеп утырып чәй эчәргә дә насыйп булмады инде, китәргә туры килде», – дип уфтаныбрак кайтып кергәнен хәтерлим. Шул очрашудан соң озак та үтми, әтием бакыйлыкка күчте.

Бер гомер

Ураза дигәннән, Наил абыйның әтисе Григорий – чуаш милләтеннән. Гомере буена ислам кануннары буенча яшәгән. Күргәннәре турында хәтта тыңлап кына утырсаң да, китап язарлык. Хәер, андый китап бар да инде ул. Улы гаиләсе һәм туганнары өчен дип нәшер иткән.

Наил абый белән без әтисенең сугыш елларына кагылышлы мизгелләрне тагын бер кат яңартып алдык. Григорий Донбасс шахталарында эшләгән, шуннан армиягә алынган. Немецлар басып кергәндә, Польша чигендә хезмәт иткән. Хурлыклы чигенү, иптәшләрен югалту ачысын мулдан татыган.

– Әтием беренче көннәрдән үк әсирлеккә эләгә. Аларны товар вагоннарына төяп, Көнбатышка алып китәләр. Сөйләвенчә, анда утырып та, ятып та, хаҗәтеңне үтәп тә булмаган. Ашарга да бирмәгәннәр. Берничә көн барганнан соң вагоннарга тозлы балык ыргытканнар. Су бирмәгәннәр. Әтием ашамаган, түзгән. Ә ашаганнарның күбесе эче авыртуга түзә алмыйча, җан тәслим кылган. Лагерьга килеп җиткәч, аларга яп-ялангач калганчы чишенергә кушалар. Әтием – үзе Петров Григорий Павлович, үзе сөннәтле, аны яһүдләр белән бергә атарга хөкем итәләр. Мин татар дип, көчкә-көчкә үлемнән котылып кала ул. «Юк кына әйбер өчен дә кыйнадылар, аттылар», – дип искә ала иде лагерь тормышын. Соңрак бер хуҗалыкта эшли башлый. Бәрәңге җыйганда, союзниклар самолеты шартлаткычлар ташлап китә. Берсе шартламый. Әтием, бу яхшы нәрсә түгел инде, кеше үтерер өчен дип, ала да артка таба ыргыта. Кирәк бит, ул немецлар өчен бик кирәкле торба өстенә килеп төшә, шартлый. Овчаркалар белән автоматлар аскан немецлар йөгереп киләләр дә: «Кем эше бу?» – дип сорыйлар. Әйтмәсәгез, һәр өченче кешене атабыз дип яныйлар. Берәү дә аңа төртеп күрсәтми, әмма кеше үтертеп булмый бит инде дип, әтием алга чыгып баса. «Мине ике катлы бинага алып менделәр. Беренче катта төрле биеклектәге дар агачлары, балаларга яраклысы да бар. Биегрәгенә күзем төште дә (әтием озын буйлы иде), монда мине асарлар инде, дип уйлап куйдым. Тик ышаныч соңгы чиккә кадәр кала икән әле ул. Мине эшләтүче карт немец та шунда булып чыкты. Ничек булды, шулай сөйләп бирдем. Теге немец та артык гаепләмәгән, ахры. Мине төрмәгә илтеп яптылар», – дип сөйли иде ул безгә.

Менә шунда Муса Җәлил белән күрешә дә инде ул. Улы әйтүенчә, исән-сау котылып кайткач, шагыйрь васыятен җиренә җиткереп үти. «Анда ачлык, әсирлектә булганнарны эзәрлеклиләр, төрмәгә утырталар, моннан китмәгез», – дип кыстасалар да, чит илдә калырга ризалашмый. Нишләтсәләр дә, илемдә үләм, дип кайта.

– Әтием рус, татар, чуаш, немец, француз, украин телләрендә җиңел аралаша иде. Чит телләрне әсирлектә өйрәнеп кайткан. Мин аның бу чаклы телне шул дәрәҗәдә ничек өйрәнә алганын хәзер дә аңлап бетерә алмыйм. Сәләте булгандыр, күрәсең, – дип искә ала Наил абый. – Бик матур җырлады, эчмәде, тартмады, биш вакыт намаз укыды. Тормышта ни бар, барысыннан да канәгать булып, гел шагыйрь васыятен искә алып яшәде.

Наил абый Кәлимуллин Алан-Бәксәр мәктәбендә татар теле һәм тормыш иминлеге нигезләре фәннәрен укыта. Мәктәптә ел саен герой-шагыйрьгә багышлап төрле чаралар оештыра ул. Анда шигырьләр сөйләнә, җырлар җырлана, видеоязмалар күрсәтелә.

– Ләкин күңелгә барыбер нидер җитми, – ди Наил абый. – Тарихны тагын да күбрәк, тулырак өйрәнәсе килә. Иң мөһиме, яшь буынга өйрәтеп калдырасы иде. Балалар бай тарихыбызны белмиләр, шуңа күрә горурлану хисе дә юк. Югыйсә татар халкының байтак язучылары, шагыйрьләре сугыш ачысын үз җилкәләрендә кичергән бит. Берсе дә тез чүкмәгән, иҗат итүдән дә туктамаганнар. Ә без алар хакында бик аз беләбез.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Гаҗәеп дөнья

«К» дип саташу

Арча районының Кәче мәктәбе укытучысы Хәйдәр Зәйнуллин «к» хәрефеннән башланган 30263 сүздән торган «Кәрим коесы» дип исемләнгән хикәя язган. Хезмәте Россия рекордлар китабына керер дигән өмете дә бар аның.



Хәйдәр Зәйнуллин үзе – Пөшәңгәр авылы егете. Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетын тәмамлаган. Хезмәт юлын Утар-Аты мәктәбендә физика, математика, астрономия укытучысы буларак башлый. Тик ул үзен нигәдер «физкультурник» дип таныштырды. Димәк, спорт күңеленә якынрак. Берүзенә ике кушамат: «Фанат» һәм «К». Соңгы ярлык шушы китап аркасында тагылган. Заманасында төрле мәктәпләрдә барлыгы тугыз фәннән укыткан ул. Хәзерге вакытта Кәчедә физкультура, физика, ОБЖ фәннәрен укыта. Шул ук вакытта берничә мәктәптә һәм Арча укучылар сараенда шашка түгәрәкләре, Арча педагогия көллиятендә шахмат-шашка түгәрәкләре алып бара. Аның укучылары – шашка, шахмат, өстәл теннисы, өстәл хоккее, бадминтон, волейбол, милли көрәш, гер күтәрү һәм башка спорт төрләре буенча район чемпионнары, призерлары. Ә бер укучысы – Татарстан һәм Россия чемпионы. Хәйдәр абыйның үзенең дә спорттагы нәтиҗәләре куанычлы. ГТО тапшыру буенча республика зона ярышлары призеры, райондагы дартс, шашка, 100, 400, 600 метрга йөгерү буенча узган ярышларда күп тапкырлар чемпион булган.

Язган китабы турында тәмләп сөйләде ул. Ә иң күңелгә ятканы: «Татар теле бик бай ул! Бер генә төрле хәрефтән башланган сүзләрдән дә калын китап язарга мөмкин», – диюе булды.

– Кызым Чәчкәнең 8 нче сыйныфта укыган чагы иде. Татар теле укытучысы Фәрдия Нәбиуллина бары бер генә төрле хәрефтән башланган хикәя төзергә кушкан. Эштән кайтсам, Чәчкәбез, тырыша-тырыша: «Кәрим белән Кәримә Каенсар авылында кое казый», – дип хикәя язып маташа. «Әти, булыш әле», – ди. Бергәләп ике битлек язма яздык.

> Көтү кугач, күрше Кафиянең куе кыйгач кашлы кызы Кәримә кое кырыена Кирлемән кушаматлы (Кирлемән кебек кире) кызгылт-көрән көчеген китереп куйды. Кыз, канатланып, Кәрим кырыенда кайнашты: кадаклар, кырык килограммлы кувалда, кәкрәйгән кадакларны кире кузгатып кагарга киләшчә китерде. Көчеге кырыена килгән кош-кортны кугалады, Кәрим кузгаткан кәс кисәкләрен комачауламаска кырыйгарак күчереп куйгалады....

Сыйныфташлары ике җөмлә дә төзи алмаган. Ә безнекен укытучысы мактаган, – ди 53 яшьлек Хәйдәр Зәйнуллин. – Ике айдан соң әлеге язманы дәвам иттерергә булдым. Мәктәптән кайтып, эшләрне бетергәч, каләм тибрәтергә утырам. Кичке 11дән төнге 2гә кадәрге сәгатьләрнең сихри көче шундый зур. Әллә нинди кызыклы әйберләр язарга этәрә. Дүрт ел дәвамында китапның беренче кисәге язылып, басылып чыкты. Ул вакытта ул 17 мең 438 сүздән тора иде. Район китапханәсендә китапны халыкка тәкъдим итү кичәсе булды. Арча районы җитәкчелеге ярдәме белән басманы 200 данә бастырдык. 2020 елда коронавирус сәбәпле, өйдә укытырга туры килде. Шул вакытта вакытны бушка уздырмадым. Тагын өч елдан икенче өлешен тәмамладым. Тугыз ел Каенсар авылы тормышы белән яшәдем. Кызык, «к» хәрефе бер тапкыр да төшкә кермәде. Ә менә китапны укый-укый кайберәүләрнекенә керергә дә мөмкин.

Кесәсендә һәрвакыт каләм белән кәгазь йөрткән. Берәр фикер килсә, тиз генә язып куйган. Иң мөһиме – вакыйгаларны бер-берсенә бәйләп, эзлеклелекне югалтмау. Җөмләне башлап, аны тәмамлау җиңел түгел. Иң озын җөмләсе – 325 сүзле.

Хәйдәр абый әйтүенчә, әсәрдә XX гасырның 60 нчы елларыннан алып хәзерге көнгә кадәр Каенсар авылы тормышы тасвирлана. Төп герой – Кәрим. Аның тулы бер гомерен чагылдыра. Ул – күпләргә үрнәк шәхес. Күрше кызы Кәримә белән гаилә корып, кешеләргә игелек кылып, авырлыкларны бергәләп җиңеп яши. Картлык көннәрендә дә бәхетле гомер кичерәләр.

Китапка «Кыш килде» дигән хикәя, «К» хәрефеннән башланган котлаулар, кроссвордлар, киңәшләр, кульъязмалар, берничә көйгә сүзләр һәм башкасы кертелгән. Бер котлавы чыгарылыш сыйныф укучылары өчен махсус язылган.

Аннан тагын башка хәрефтән хикәя язу теләген дә сораштык. Менә бу урында шикләнеп куйды. Әлегә аның өчен иң бай хәреф – «к». Бәлкем, башка хәрефтән кечкенә хикәяләр язар.

Аның кебекләр тагын бармы? Николай Культяпов 16 мең «о» хәрефе белән башланган «Ольгин остров» дигән юмористик әсәр язып, Гиннесның Рекордлар китабына кергән икән. «Берәр битле өзекләр укыган бар, тик минеке кебекне күргәнем юк. Бәлкем, мин дә хикәям белән рекорд куярмын», – ди укытучы.

Хәзерге вакытта Хәйдәр Зәйнуллин «Шашка уйный беләсеңме?», «Гаилә иҗаты», «Кызыклы мизгелләр» дип исемләнгән китаплар яза. Бер каләм җене кагылса, тиз генә чыкмый шул ул. Хәйдәр абый безне әллә ниләр белән шаккатырыр әле.

Сәрия МИФТАХОВА

Хәтер-хатирә

МУЗЕЙ БАБАЙНЫ САГЫНЫП

Безнең Яңа Чишмә районында Зирекле дигән матур исемле, тырыш халык яшәгән бер авыл бар. Һәм анда безнең якларда гына түгел, даны еракларга таралган музей эшли. Ул музей турында кемнәр генә язмады инде, нинди генә зур шәхесләр булмады анда. «Россиянең иң мәртәбәле кешеләре» исемлегенә кергән, халыкта гади генә «Музей бабай» дип йөртелгән Мидхәт ага Газыймов тырышлыгы бу.

Кызганыч, 2022 елда безнең арадан китте агабыз, быел гыйнварда аңа 82 яшь булыр иде. Минем бу язмам исә Зирекле халык иҗаты һәм көнкүреше музееның бүгенге директоры Лидия Лотфуллина турында. Әлбәттә, Остазы турында да. «Мидхәт абыйның эшенә генә түгел, бар тормышына сокланырлык. Мин аның белән 25 ел эшләдем. Мидхәт абыйда булган максатчанлык, җаваплылык, кешелеклелек, бик зур төгәллек белән һәр эшне вакытында һәм җиренә җиткереп башкару кебек сыйфатлар минем өчен зур үрнәк булды. Ул минем укытучым да, җитәкчем дә, киңәшчем дә иде. Абыйга хөрмәтем һәм рәхмәтем чиксез», – ди ул. Һәм санап китә… «Мәгълүмат җыйды, бөртекләп фактлар, саннар тикшерде, хатлар язды, авылга нигез салынуның күпкә иртәрәк булуын исбатлау өчен дәлилләр эзләде, очрашулар оештырды. Зирекле авылы тарихы, аннан чыккан күренекле шәхесләр, имамнар, һөнәрчеләр, сугыш корбаннары һәм ветераннар, туган авылыбызның халык авыз иҗаты, бәетләре, мөнәҗәтләре, географик атамалары, гореф-гадәтләре турында документаль китаплар язып калдырды. Зирекле авылы тарихы буенча алты китап басылып чыкты. («Зиреклем зирекләре», «Мәктәбем, син – үскән бишегем», «Сугыш өткән еллар», «Яңа тормыш»та – яңача» һ.б.). Бөек Ватан сугышында һәлак булган, хәбәрсез югалган якташларыбызның исемнәрен ачыклауда, аларны Хәтер китабына кертүдә дә өлеше зур Мидхәт абыйның. Йөзләрчә райондашларыбызның исемнәре ачыкланды, аларның оныклары, туганнары күп рәхмәт сүзләре җиткерделәр. Әфган, Чечня сугышларында катнашкан авылдашларга, якташларга багышланган китаплар бастырылды…»

Әйе, Мидхәт абый, нәкъ Лидия ханым әйткәнчә, үзе белән һәрвакыт кечкенә генә блокнот, ручка яисә карандаш йөртте, бернәрсәгә дә вак-төяк дип карамады. Бүген исә бу эшләр барысы да Лидия ханым өстендә. Ул үзе дә – Зирекле кызы. Очрашып йөргән егете Әфганстанда хезмәт иткән чагында: «Әгәр исән-сау туган җиргә әйләнеп кайта алсам, авылда әти-әнием янында яшәрмен», – дип нәзер әйткән булган. «Мин аның сүзләрен аяк астына салып таптый алмадым. Без төп йортта каенана-каената белән гомер иттек. Аларның риза-бәхиллеген алып, матур итеп яшәдек», – ди ул, һич үкенмичә.

Ел саен уздырыла торган Шигырь бәйрәме дә – Зирекле музееның традицион чарасы. Ул апрель аенда Тукай туган көндә мәгариф бүлеге белән берлектә үткәрелә. Ел саен музейга район мәктәпләреннән каләм тибрәтүче укучылар һәм шигъри җанлы өлкәннәр җыела. Биредә укылган шигырьләрне туплап, уңышлыларын җыентыкларга кертәләр.

2014–2022 елларда Мидхәт абый Яңа Чишмә районының «Бөреләр» әдәби берләшмәсен җитәкләде. Районда гына түгел, тирә-як төбәкләрдә дә каләм тибрәтүчеләрне барлап, оештырып, берләштереп торды. Китаплар, альбомнар эшләде… Мидхәт Газыймовның турыдан-туры ярдәме һәм киңәше белән музей 54 китап бастырып чыгаруга иреште, шуларның унтугызы – якташ язучылар иҗаты. Унсигез авторның егерме тугыз китабы, дүрт коллектив җыентык дөнья күрде. 2023 елның декабрендә «Рухият» фонды белән берлектә эшләнгән «Әдәби офыклар» китабына тугыз якташыбызның шигырьләре кертелгән. Соңгысы инде – Лидия ханым тырышлыгы. Хәзер бу эшләрне ул үз өстенә алган.

Зирекле музееның үзенчәлекле бер юнәлеше – бәетләр туплау. Хәзерге көнгә «Хәтер тамчылары» исеме астында басылып чыккан ун китапка 833 бәет кертелгән. «Бу байлык Татарстанның ун районыннан җыелды, Мидхәт Гариф улының үзе иҗат иткән 111 бәете «Тормыш чоңгыллары» дип исемләнгән җыентыкта укучы кулына килеп ирешә», – ди Лидия ханым.

Ниләр сөендерә, ниләр көендерә бүген музей хезмәткәрен? «Кичәге көн ул инде – бүгенге тарих. Әле дә ярый безнең авылда музей – мирасханә бар, монда бөтен авыл халкының тарихы саклана, дип сөенәм», – ди ул.

> **Музей хезмәткәрләрен борчый торган мәсьәләләр дә хәтсез. Әйтик, музейлар эшләгән акча хәзер эшне бәяләү күрсәткеченә әверелеп бара. Бу исә мирасханәләрнең иҗтимагый асылын юкка чыгара. Күңелне борчыган нәрсә – фондларны саклау өчен бина проблемасы. Коллекцияләр елдан-ел ишәя, аларны урнаштыру, XIX–XX гасырларга кагылышлы ядкәрләрне күрсәтү кыенлаша бара.**

Музейның гаять бай үз китапханәсе барлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Анда 30 ел буе берәмтекләп җыелган сирәк китаплар, тарихи томлыклар, сүзлекләр, энциклопедияләр, татар тарихына караган хезмәтләр, матур әдәбият һәм төрле елларда чыккан газета-журналлар саклана. Кыскасы, музейның китапханәсендә биш мең китап исәпләнә. Музей өчен зур бина, һич югы өстәмә корылма булдыру Мидхәт абыйның да күптәнге хыялы иде. Дөрес, музей утыз елдан соң төзекләндерелгән матур, якты бинага күчте, ләкин ул тагын да кечерәебрәк калган инде.

Узган ел ук музейга Мидхәт Газыймов исемен бирүгә ирешкәннәр, «Мидхәт Газыймов – «Музей бабай» дигән китап нәшриятка тапшырылган. Аны Мидхәт аганың кызы журналист Алсу Шәрипҗанова белән берлектә әзерләгәннәр. (Сүз уңаеннан, оныгы –

танылган хоккейчы Дамир Шәрипҗанов белән бик горурлана иде бабасы.) Озакламый ул китапны тәкъдим итү эшләре башланачак.

Татарстанның сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова музейга килгәч, биредәге кызыл башлы сөлгеләрнең күплеген һәм алардагы бизәкләрнең бер-берсен кабатламавын күреп, бу кадәр коллекция Татарстанда бер генә, дип гаҗәпләнә. Әлеге сөлге үрнәкләре бүген 350гә җиткән. Сөлгеләрнең төп өлеше – Зирекле халкының кул эше. «Менә шул сөлгеләрнең каталогын булдыру өстендә эшне башладык. Бу ниятебезне тормышка ашыруда этнографларның, белгечләрнең зур ярдәме кирәк булачак. Күз курка, кул эшли, диләр. Аллаһы Тәгалә ярдәмен бирер, иншә Аллаһ!» – ди Лидия Лотфуллина, тагын бер ниятләре белән уртаклашып.

«Дөньяда нинди генә хәлләр барса да, тарихыбызны, рухи мирасыбызны сакларга кирәк», – ди Лидия Лотфуллина. «Аяклы энциклопедия» дип саналган абыйсын сагынып, юксынып яшәсә дә, зур шәхесләрдән соң аеруча зур тырышлык, фидакарьлек кирәклеген аңлап эшли бүген үз остазының лаеклы дәвамчысы.

Лилия ФӘТТАХОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

И-И БАЛАЧАК...

Мәңге үтмәс кебек тоела иде ул. Абыйлардан калган киемнәрне киеп, шыгырдап торган кар өстеннән болын буйлап мәктәпкә бара идек. Укудан кайткач, бер телем кара ипигә каймак ягып чәй эчкәч, әти кушып калдырган эшләрне эшләгәч, урамга уйнарга чыгабыз. Эшләү мәҗбүри, таләп үтәлмәсә, икенче көнне уйнарга чыгармаулары да ихтимал. Эштән соң рәхәтләнеп чана шудык, койма буйларында, тирләп-пешеп, үзебезчә окоп казыдык, уеннар уйнадык. Уеннан вакытында кайтмасак, әти-әни эзләп тә чыга иде. Утыз градуслы салкыннар да өркетмәде безне. Әле ярый компьютер дигәннәре юк иде, югыйсә урамдагы уеннардан, хәзерге балалар кебек, колак каккан булыр идек. Без бит үзебез уеннар уйлап чыгарып, рәхәтләнеп уйнап буй җиткердек. Уйнарга уенчык булмагач, шакмакны шакмакка кадак белән кагып, трактор ясый идек. Менә шунда чүкеч тотып, бармакка суга-суга, кадак кагарга да өйрәндек. Җитмәүчәнлек адым саен сиздереп торса да, күңел күтәренке иде, төшенкелекнең ни икәнлеген белмәдек, өйдә моңаеп утырмадык. Барыбыз да бер тиң иде, көнләшергә уйлап та карамадык, дуслыгыбыз чып-чын иде.

Яз көне тау битләре кардан арчылгач, какы, кузгалак, кычыткан, песи борчагы җыеп ашап, тәнгә рәхәтлек туплый идек.

И-и балачак, балачак, һич онытылмас балачак.

Раил ҺАДИЕВ

Моңлы сандугач

Радиодан, телевидениедән халык җырчысы Рәшит Сөләйманов башкаруында җыр яңгыраса, ничектер күңелгә рәхәт булып китә. Аның тавышын беркемнеке белән дә бутап булмый.

Рәшит Чистай районының Иске Роман авылында туа. Колхозда аш пешерүче Маһирә апа белән тракторчылар бригадиры Шакирҗан абзый гаиләсендә биш кыз – Мәрвия, Фәүзия, Наҗия, Нәкыя һәм Роза арасында бер малай булып үсә ул. «Әнием бик матур җырлый, Сабантуйларда һәрчак беренче урынны ала иде. Әтием – оста гармунчы. Дин юлында булганлыктан, яшереп кенә уйнады», – дип сөйли иде Рәшит Сөләйманов.

Әтисе мөнәҗәтләр әйтергә яраткан. Мөгаен, Рәшитнең сәхнәгә омтылуы да сәнгатькә гашыйк әтиәнисеннән башлангандыр. Кечкенә вакытта малай бик оялчан була, әтисеннән отып калган мөнәҗәтләрне качып кына җырлый.

Сугышта аягын имгәтеп кайткан Дан орденнары кавалеры әтисен чанага яисә арбага утыртып, авылның икенче башына мич чыгарырга алып барган мизгелләрне дә сагынып искә ала иде ул. Әтиләре сугыш яраларыннан вафат булгач, 1969 елда 8 нче сыйныфны тәмамлаган Рәшитне Уфада яшәүче Фәүзия апасы белән Әдһәм җизнәсе Мәүлиевләр үз яннарына алдыралар. Үсмер егет, укуын кичке мәктәптә дәвам иттереп, Уфа шәһәрендәге заводларның берсенә токарь ярдәмчесе булып эшкә урнаша. «Кызыл таң» газетасында эшләүче җизнәсе, каенише күңелендә яткан моңны тоеп, аны баян буенча түләүле кичке түгәрәккә йөртә башлый. Ул өч ел рәттән Уфа сәнгать училищесына укырга кереп карый, әмма уңышсыз була. Үҗәтләнеп, дүртенче мәртәбә бара һәм теләгенә ирешә.

Аны заводта токарь булып эшләгәндә үк Уфа опера һәм балет театрының хорына алалар. Опера – аның өчен үзе бер мәктәп. Училищеда укыганда ук «Салават Юлаев», «Князь Игорь», «Борис Годунов» кебек операларда, күп кенә комедияләрдә уйный-җырлый. Озын буйлы булганга, аңа Дон Кихот ролен уйнарга да тәкъдим итәләр.

Консерватория тәмамлагач, язмыш аны янә Уфа якларына озата. Ул «Энергетик» мәдәният сараенда вокаль ансамбль җитәкчесе булып эшли. Балаларны җырларга өйрәтә. Концертлар куеп йөри. Тик күңеле барыбер Казанга тартыла. Рәшитне Лима ханым Кустабаева җыр һәм бию ансамбленә солист итеп чакыра. Ул анда «Кошлар кебек», «Рәйхан», «Болын», «Тәфтиләү», «Туган тел», «Кара урман», «Сарман», «Зөбәрҗәт» һ.б. халык җырларын җырлый.

Артист халкының гомере юлда үтә. Рәшит тә дөньяның кайсы гына кыйтгаларында булмаган да татар моңын кайларга гына таратмаган! Ә дистәләгән җырлары «Татарстан» радиосы һәм телевидениесенең алтын фондында саклана.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

Илдар Мөхәммәтҗанов

Игелек хисе

Йөрәктә әнкәм сөтеннән
Күчкән игелек хисе.
Урман, кырлар, тау, туганнар,
Күл, чишмәләр, күк,
тургайлар –
Мөкатдәс бөтенесе.

Соң чиккәчә күзләремдә
Уңмас туган як төсе.
Ничек дөрләп кабынмаска?
Җанымда – ут яктысы.

Айрат СУФИЯНОВ

ШАКИРӘ АПА ОШАТТЫ

Һәр чорның үзенә күрә шомлы да, якты да вакытлары була. Элеккерәк заманнарда, тәүге хезмәт адымымны радиоузелда башлаганда, әлбәттә, язу-хәбәрчелек белән дә җенләнгән вакытта, миңа абзый-апалар авылдагы кайбер хәлләр хакында гел сөйләп, колак итемне ашыйлар иде. Билгеле, үзем дә күрәм боларны, тик берни алга таба эшләнми, гел кирегә дигәндәй, колхозыбыз – районда иң арттагылар рәтендә. Җитәкчеләрне әледән-әле алыштырып торсалар да, алгарыш адымнары төштәге-хыялдагы сыман. Укучы вакытларымнан Казан газеталарында язмаларым гел чыгып торганга күрәме, абзый-агайлар, егет-җилән, миннән ни-нәрсәдер көтә иде. Күрәсең, чиге килеп җиткәндер: мин бер кичне, төн буе утырып, үзем белгән-күргәннәрнең иң борчыганнарын язып, турыдан-туры ТАССР Югары Советына юлладым. Почеркым, кем әйтмешли, печать түгел, мәктәп күләмендә үрнәк иде.

Менә озак та үтми, безнең Югары Стәрле авыл Советы, клуб тирәләренә бомба төшкәнмени – халык ыгы-зыгы килә. Ул да булмый, минем радиоузел бүлмәсенә бик ыспай киемле, галстуклы кешеләр килеп керә. Райкомның беренче секретаре, тагын әллә кемнәр.

– Син яздыңмы бу хатны? – диләр.

– Әйе, мин.

– Кемнәр әйтеп торды?

– Беркем дә!

– Дөрес түгел бит?

– Дөреслеген халык әйтер!

– Ялгышлык, кызулык белән дип уйламыйсыңмы? Шулай дисәң, тикшереп тормыйбыз – мә, кул куй!

– Халык әйтер!

Шулай булды да: клубта тикшерүчеләргә каршы чыктылар. Монда килгән партия райкомының идеология секретаре Шакирә апа Шәрәфетдинова минем күңелемдә менә хәзер дә, моңа ярты гасырдан артык вакыт үтеп тә, бу җәмгыятьтә ничек яшәргә икәнне күрсәтеп калдырды.

– Бу егет белән шаярмагыз, ул һәммәсен дә дөрес-хак күргән һәм язган, – дигән иде ул мондагы җитәкчеләргә. – Яшьләр белән эшли белергә, аларга гаделбулырга, әйбәт эш шартлары тудырырга, мәгариф, культура, спортны күтәрергә-үстерергә кирәк.

Әлбәттә, агайлар белән киңәшеп язган хатның файдасы зур булды, авыл җитәкчелегеяшь кадрлар кулына күчте. Монда аеруча тормышның төбеннән күтәрелеп, ягъни тракторчыдан алып бригадирлыкта хезмәттә чыныккан Заһир абый Кашаповның фидакарьлеге аерым мактауга лаек. Утыз елга якын туган авылын-колхозын җитәкләп, ул районда гына түгел, республика күләмендә алга чыгарды – шул Шакирә апа әйткән мәгариф, медицина, культура, спортта уңай шартларны тудырды. Күп орденнар иясе, Татарстан Югары Советы депутаты. Күптән түгел аның истәлегенә мәдәният йорты диварында хәтер тактасы ачылу хезмәтен бик тә зурлау иде.

КПСС райкомы секретаре Шакирә апа мине дә ошатты – гомерем буе журналист булып эшләвемдә үземне аңа бурычлы саныйм. Күпләргә олы игелекләр кылган бик тә ярдәмчел, якты күңелле хатын-кыз җитәкче иде. Республикабызның дәүләт эшлеклесе Әнвәр Баһаветдинов белән озак еллар хезмәттәшлектә, Сәләй авылында туып, илебез чәчәк атсын өчен бөтен эшентырышлыгын куйган Шакирә Сәлах кызының исеме дә онытылмаска тиеш!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Фикер

БЕРАЗГА ГЫНА БУЛСА ДА...

«ВТ» архивыннан. Фото бизәү өчен тәкъдим ителә

Тормышта һич тә уйламаган, көтелмәгән хәлләргә тарасың икән кайчак. Шул уңайдан бер мәзәк сөйләп узыйм әле.

Бер ханым иртән иртүк урамнан җил-җил эшенә ашыга икән. Кыш көне иртәнге якта да бик тиз генә яктырмый. Бу ханым игътибар белән караса, сиксәннең өске ягындагы бер әбекәй кичтән ишеп яуган карны кызу-кызу көрәп ята. Аның: «Ник бераз яктырганны көтмисең, караңгыда ук чыгып тотынмасаң да була ич?» – дигән соравына теге әби: «И-и балакаем, көрәмәс идем дә, скорый чакырткан идем, керә алмыйча борылып китәрләр дип куркам», – дип җавап биргән.

Күптән түгел үземә дә әлеге бичара әби хәлендә калырга туры килде. Эштә утырганда кинәт кенә күз алдында томан пәйда булды. Янымдагы хезмәттәшем: «Син бит ап-ак булгансың», – диде, шул арада тиз генә баллап чәй эчерде. Күпмедер вакыттан соң бу халәт бераз узган кебек булса да, ашыгыч ярдәм бүлегенә барып, кан басымын үлчәтеп килергә булдым. Ул көннәрдә һава температурасы да бер төшеп, бер күтәрелеп уйнаклап алды, өстәвенә минем гемоглобин да төшеп бимазалаган чорлар иде.

Хуш, ашыгыч ярдәм бүлегенә килеп кердем шулай. Пульт артында дежур хезмәткәр генә утыра. Мин аңа үземнең борчуымны аңлатып бирдем дә, «көтегез!» дигән җавап алгач, чакыру буенча чыгып киткән табибларны көтеп утыра башладым. Тик эштән сорап кына китү сәбәпле, озак утыра алмаячагымны аңлап, пульт артындагы теге ханымга, тагын күпме көтәсе булыр икән, дип мөрәҗәгать иттем. Ике ашыгыч ярдәм бригадасы ул көнне Әлмәткә киткән булып чыкты, ә берсе шәһәр буенча чакырулар алган икән. Ул арада тагын якындагы бер авылдан ниндидер авыр хәлле авыру буенча хәбәр килде, аннан шәһәрдән берәү тизрәк килүләрен үтенеп шалтыратты. Кыскасы, миңа кире борылып китүдән башка чара калмады. Алай да теге ханым больницаның кабул итү бүлегенә барып килергә киңәш итеп калды, рәхмәт төшкере...

Менә шул вакытта мин үз сәламәтлегең өчен беренче чиратта бары тик үзең җаваплы икәненә тагын бер кат инандым. Нинди генә авыр хәлдә калсаң да, паникага бирелмәскә, үзеңне кулга алырга тырышырга кирәк. Ә инде хәлең бик авыр булса, якыннарыңнан тиз арада больницага илтүләрен үтенү зарур. Гомернең һәр минуты санаулы икәнен соңгы еллардагы үлем-китемнәр дә безгә еш искәртеп тора.

Бер карасаң, шундый озын кебек, ә чынлыкта исә, ни кызганыч, бер мизгелгә генә тиң шул ул кеше гомере. Кайчакта күзләрне чытырдатып йомасы да уйларны иреккә җибәрәсе, баштагы бөтен борчуларны алып ташлап, якты киләчәккә планнар корасы, аларны әкрен-әкрен генә тормышка ашырасы килә. Тик, ни кызганыч, барысы да без уйлаганча гына булып чыкмый. Уйлап баксаң, күпме кешенең тел очында бик-бик әйтергә теләп тә әйтелмәгән сүзе, чынга ашмаган хыяллары, аяк басарга өлгермәгән җирләре, йокланмаган күпме төннәре, атмаган таңнары, түләнмәгән әҗәтләре, кылынмаган догалары, төзәтергә өлгермәгән хаталары, татылмаган нигъмәтләре, эчелмәгән сулары, үтелмәгән юллары, тупырдатып сөелмәгән бала-оныклары, бирелмәгән киңәшләре, эшләнмәгән эшләре, яуланмаган үрләре, җырланмаган җырлары кала... Өлгерәсе иде, җитешәсе иде матур итеп яшәп калырга, тышаулыйсы иде яшен тизлегендә үтеп баручы гомер аргамагын. Тик беразга гына булса да...

Гөлчәчәк САДРЕТДИНОВА

Кайгы-хәсрәт ташкыны

Димәк, яратмаган...

Ир белән хатын арасында хисләргә кайнарлык өстәп торучы иң нечкә кыл шул көннән өзелде. Бу очрашуга инде дистәләгән еллар үтеп китсә дә, аның йөрәкне айкап алырдай моңлы-сагышлы тавышы һаман да колак төбендә. Кыядан ташланырга әзерләнгән горур бөркеттәй карашын зәңгәр күктә агылган болытларга төбәп, шактый озак дәшми утырганнан соң ул: «Мин аны яраттым», – дип куйган иде. Әнә шулай бер җөмлә белән, әйтәсе килгәнен, күңелендә йөрткәнен гади итеп, әмма сүзләренә никадәрле тирән мәгънә салып... «Әгәр дә миңа: «Иреңә бөереңне алып бир», – дисәләр, бөеремне алып биргән булыр идем. «Күзеңне алып бир», – дисәләр, күземне алып биргән булыр идем». Бу сүзләргә өстәп, тагын ни әйтәсең?!

Икең дә ратканда гына сөю бәхеткә әйләнә шул ул. Димәк, яратып өйләнмәгән. Эчемнән шулай уйлый-уйлый, аның әкрен генә сөйләгәнен тыңлыйм. Юк, алар яратышып өйләнешкән. Егет аны бер күрүдә ошаткан. Аның: «Озак йөрмәдек, гаилә корып җибәрдек. Бәхетле идек без», – дигәне истә. Аннан аларның тормышларын тагын да ямьләндереп, балалары туган. «Сабыйга өч ай булганда, сәер үзгәрешләр башланды, – дип инәлгән иде шул чагында сердәшем. – Кайларга гына йөртмәдек, нинди табибларга гына күрсәтмәдек. Нәтиҗәдә алар, дәвалый торган чир түгел, берни эшләтә алмыйбыз, дип, соңгы сүзне әйттеләр. Тора-бара сөекле ирем дә алыштырып куйгандай булды. Үзгәрде ул. Балага күз дә төшерми, бишеген әйләнеп уза. Эштән дә гадәттәгедән соңгарак кайта башлады».

Үз кичерешләренә бирелеп, үз эченә йомылып яшәргә күнекмәгән хатын бу бәладән фаҗига ясарга җыенмаган, әлбәттә. Аннары... ялгыз түгел ич ул, янында һәр эштә терәк булырдай ире бар. Шулай уйлаган булган, тик ялгышкан. Өй, бала мәшәкатьләренә чумып, иренең аңа карата салкыная башлавын, гаиләдән гаме китүен абайламый да калган. Көннәрнең берсендә, яралы күңеленә җәрәхәт өстәп, «ирең йөри» дигән хәбәр килеп ирешә. Хатын ышанмый. Ә бәлкем, сиздермәскә тырышкандыр. Барысы да билгеле була бит инде. Авыру бала белән ялгыз калулары җиңел булмас. Ул иң элек шул хакта уйлый.

Ләкин ир белән хатын арасы саклап кала алырлык булмаган шул инде. Бичара хатынның: «Аерылып китте дә, килеп, безнең хәлебезне дә белмәде, – дигәне хәтердә. – Бәхетне без икебез ике төрле аңлаганбыз икән».

Әйе, кемгә – нәрсә... Ана кеше өчен беренче урында – бала. Ул баласы өчен җанын бирергә әзер. Хатынын, гарип баласын ташлап китеп, үз рәхәтенә яшәп яткан әтиләрне (әтиләр дип әйтергә тел әйләнми) дә, әнә шулай, танышым шикелле, баласына чәйнәп ашата, күтәреп мунчага алып бара, юындыра, ә төннәрен, газизен өянәгеннән саклап, янында уздыра торган батыр йөрәкле, шәфкатьле әниләрне дә күп күрдем мин.

– Әгәр дә ирең көннәрдән бер көнне кире кайтса, гафу үтенсә, кабул итәр идеңме? – дип сорыйм. Юк инде, аларның хисләре күптән суынган. Алар хәтта бер-берсенә үпкә-ачу да саклар хәлдә түгел.

Әлбәттә, әтиләрнең дә, әниләрнең дә төрлесе бар. Яңа туган баласын чүплек савытына, балалар йортларының ишек төпләренә ташлап киткән рәхимсезләр дә җитәрлек. Азмы ишетәбез алар турында. Ире эштә чагында дүрт яше дә тулмаган инвалид коляскасындагы кызчыгын апасына (ә апасына – ун яшь) калдырып, өйдән чыгып киткән хатынның алга таба яшәргә ничек көче җитәдер (шул чагында «йөргән кешесенә качкан» дигән сүзләр таралды), кем шундый хатынны кабул иткәндер – белмим. Ничек ире бу хәлләргә түзгәндер?! Хатын-кыз барына да түзә, ә менә ир кеше... Алар яшәгән өйнең капкасын ачып кергәндә, башымда бетмәс-төкәнмәс сорау, шул мәлдә ана җылысына бик тә мохтаҗ булган сабыйлары өчен үпкә-рәнҗеш иде. Бусагадан атлап керүгә үк, йөземә авыл өйләренә генә хас рәхәт бер җылылык килеп бәрелде. Тыныч, чиста, пешкән ризык исләре... Кызлар да ни беләндер мәшгуль. Карашымны алмый күзәтүемне күргәч, «миңа булышалар» дип елмайган иде әтиләре.

Сәгатьләр буена барган аралашу дәвамында кызлар бер генә мәртәбә дә, ялгышып та, әниләрен искә алмадылар. Әйтерсең ул юк һәм булмаган да. Аның каравы әти дә әти... Әти әйтте, әти кушты... Гаҗәпләнүемне белдергәч, йорт хуҗасы: «Ул алар белән бик каты булды», – дип, мине тагын да ныграк гаҗәпкә калдырган иде. Ничек инде ул «каты булды», бу – ни дигән сүз? Соравымны бирмәдем. Болай да аңлашыла ич: киткән, ташлаган, димәк, алар ул хатынга кирәкми.

– Китсен, кире әйләнеп кенә кайтмасын, – дип озатып калган иде мине әти кеше. Бөтен авылны хәсрәткә салган бу вакыйгага карата аның – үз мөнәсәбәте.

...Бу вакыйгаларны кайта-кайта искә төшерәм дә, йөрәк сыкрап куя: и гомерләр... Ник бу дөнья шулай гаделсез, рәхимсез икән?! Ни өчен берәүләрнең бәхетсезлеге икенчеләр өчен үз тормышын җайлау чарасы булып хезмәт итә икән?! Сораулар тормышның үзе шикелле катлаулы һәм моңа җавапны һәркем үзенчә табарга тырыша.

Мәдинә АВЗАЛОВА

pinterest.com

Балык Бистәсе

АКЧАЛЫ СЕБЕРКЕ

Шөгыль

Чаллыбаш авылында яшәүчеләрнең – үз кәсебе. Алар ел әйләнәсендә мунча миллеге, урам себеркесе бәйләп сата. Күбрәк шәһәр халкы соратып ала икән. Иренмәсәң, табышы да бар, диләр. Тик шул ук вакытта табигатькә дә зыян китермәскә кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чаллыбашта 36 йорт исәпләнә, 135 кеше пропискада тора. Ә менә 16 йорт буш, анда берәү дә яшәми. Медпункт, мәчет, клуб бар. Кибет юк. Ипине һәм башка кирәк-яракны атнага өч тапкыр автокибет китерә. Юлларына асфальт түшәлгән. Кышын карны трактор ачып тора. Йортларга су кертелгән. Халкы терлек асрап, сөт сатып көн күрә. Кайберәүләр күрше авылга «Кулон» агрофирмасына эшкә йөри.

Авыл урманнан кул сузымында гына. Чаллыбашлыларны чын табигать балалары дияргә була. Алар җәен – җиләк, көзен гөмбә җыя. Үз кирәк-яракларына дип, себеркенең төрлесен әзерли. Шул ук вакытта бу шөгыльне кәсепкә әйләндерүчеләр дә бар. Моңа кадәр аны унлап йортта бәйләгәннәр. Хәзер себерке осталарының саны кимегән. Кайсы кая эшкә урнашкан.

Рәзинә Гайнетдинова – Мамадыш кызы. 16 ел элек Чаллыбаш авылы егете Раилгә кияүгә чыккан. Аның белән өч бала тәрбияли. Моңа кадәр укытучы булып эшләгән. Тик авылда эш юк. Шул сәбәпле, һөнәрен башкага алыштырырга туры килгән.

– Авылның табигатен дә, кешеләрен дә бик яратам, – ди Рәзинә. – Үземә кечкенә генә кәсеп таптым: урман себеркесе җыеп сатам. Елга 2–2,5 меңне бәйлим. Ирем урманнан алып кайтып бирә, улым сындыра, ә мин бәйлим. Бәя үзгәреп тора. Быел берсен 65 сумга саттык. Заказны шәһәрдән дә, районнардан да бирәләр. Шифасын тапканнар икенче елны да сатып ала. Әрем, бөтнек, зәңгәр һәм сары мәтрүшкәсен дә кушам. Кыйммәт дип әйтүче юк.

Нурания һәм Альфред Хәбибуллиннар исә урам себеркесе бәйләп сата. Бу – аларның күптәнге шөгыле.

– Бу эшкә көз көне агачлар яфрак койгач тотынабыз. Яз көне ярамый, чөнки сулана торган була. Каенның аскы ботакларын агачка зыян китермичә генә җыябыз. Сораучылар булганда, тик тормыйбыз. Күрше авылдан да заказ биргәлиләр. Шәһәр халкы бигрәк тә урам себерергә сорый, – ди Альфред абый. – Җыю озак, бәйләү тиз аны. Яшь вакытта җиңелрәк иде. Бу сиңа мунча себеркесе генә түгел, күп көч кирәк. Бармак башлары авыртып бетә. Хезмәте күп булса да, хакы арзан. Берсе 30–40 сум тора.

Нурания апа әйтүенчә, урманга рәхәттән йөрмиләр. Ничек тә булса яшәргә, тормыш алып барырга кирәк. Лаеклы ялга чыкканчы, алма бакчасында эшләгән ул. Анда төрле җиләк-җимешләр үстергән. Соңгы вакытта чыбык-чабык янында кайнаша. Без килгәндә, ботак кайгысы түгел иде әле аларда. Сөенечләре зурдан. Хәрби операциядә катнашучы улларының ялга кайтуын көтәләр иде.

Сәрия МИФТАХОВА

Себеркегә ботаклар җыярга ярыймы?

Айрат ӘХМӘРОВ, Татарстан урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге җитәкчесе:

– Мунча миллеге, урам себеркесе өчен һәм үрү өчен ботакларны печән чабу кишәрлекләреннән, чистартылырга тиешле урыннардан, шулай ук ауган агачлардан җыярга мөмкин. Урманнарда агачларны саклап калу таләп ителгән җирдәгесенә кагылырга ярамый. Урман байлыкларын: әйтик, сагыз, дару үләннәрен һәм башкасын җыю тәртибен бозган очракта штраф күләме гражданнарга – 500 сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 500–1000, юридик затларга 5000 сумны тәшкил итә. Моннан тыш, урман утыртмаларын зарарлаган яки агач-куакларны үз белдегең белән казып алган өчен, шулай ук штраф һәм зыянның күләме 5000 сумнан артып киткәндә, җинаять җаваплылыгы каралган.

Язмыш

Коткарып булса иде...

Казанның Тульская урамында урнашкан машина юу урынында автоцистерна эчендә ятучы ике ир-атны табалар. Аларның берсе хастаханәдә ята, икенчесен коткара алмыйлар. Әлеге ир-атларның бәлагә юлыгуы хакында 16 нчы янгын-коткару частена хәбәр килә.

Өч коткаручы – Александр Хилков, Фарух Галләмов, Рамил Шәйдуллин юлга кузгала. Мондый хәлне беренче күрүләре була аларның. Ир-атларны коткарырга дип, Рамил Шәйдуллин алар янына төшеп китә.

– Төн иде. Безнең частьтан ерак урнашмаган машина юдыру станциясенә барып җиттек. Без аларны чыга гына алмыйлардыр дип уйладык. Фаррух аларның аңсыз икәнлекләрен әйткәч, мин махсус киенеп, алып чыгарга дип аска төшеп киттем. Ир-атларга маска кидердек. Өскә чыгардык. Ул арада ашыгыч ярдәм дә килеп җиткән иде. Ахыргача, егетләрнең икесе дә исәндер дип көттек, – ди ул.

Авыр хәлдә калган кешеләргә еш ярдәм итәргә туры килә Рамилгә. Суга батучыга да ярдәмгә ашыга ул, янгын эченә дә кереп китә. Эше шундый. Тәрбиясе дә. Нәселләрендә 7 ир-ат коткаручы һөнәрен сайлаган. Әтисе 25 ел янгын сүндерүче булып эшли. Аның энесе, әнисенең ике туганы, кияүләре дә шушы хезмәттә.

– Мин бер дә бу һөнәрне сайлармын димәгән идем. Мәктәп елларында музыкага хирыс булдым. Баянда, гитарада, пианинода уйный беләм. Армиядән кайттым да коткаручы булып эшкә урнаштым. Әтиемнең үзенә ияртеп йөртүләре бушка китмәде. Шөкер, әлегә кадәр үкенгәнем булмады. Кешеләрне коткарып булса, күңелгә рәхәт булып китә. Ул хисләрне аңлатып булмый, – ди Рамил. – Төрле хәлләр белән очрашабыз. Кайчак йорт дөрләп яна. Соң чакырталар. Инде өйгә кереп булмый. Ә анда кешеләр. Шулчакта өзелә инде үзәк. Аеруча балаларның гәүдәләрен табу кыен. Без кулдан килгәнчә ярдәм итәбез, булышабыз инде. Ул чакта кешеләр бик хәсрәтле була. Иң авыр чакларын без күрәбез. Ә аннары берәр көн узып, тыныч кына ятканда алдагы көннәр искә төшеп, нинди зур эш башкарганбыз, дисең. Шаккатып та куясың.

Ул зур эш янында гомерләрне куркыныч астына кую да бар. Коткаручылар һәр сменага чыгып киткәндә, моны аңлый. Аларның әти-әниләре дә, хатыннары да якын кешеләренең хәлен яхшы белә. Бергә эшләгән егетләр дусларга әйләнә, гаиләләр туганлаша.

– 2009 елда кызым туды. Иртәгә бала тудыру йортыннан чыгаралар дигән көнне мин эштә идем. Иртәнге сигездә алышынабыз. Минутларын санап көтәм. Шулвакыт 15 минут кала, янгын хакында хәбәр килде. Барып керсәк, газ баллоннары тутырылган склад яна. Менә шунда, баламны кулларыма да ала алмыйча калам икән, дигән уй булды. Шөкер, сүндерә алдык. Хатыным Альбина белән бер-беребезне аңлап яшибез, – ди Рамил.

Гаиләдә коткаручылар күп булгач та рәхәт, ди ул. Очрашканда һәркем үз тәҗрибәсе белән уртаклаша. Төрле хәлләрне искә алалар. Әмма гел эш кенә түгел, Рамил балыкка йөрергә, мунча керергә ярата.

ОАО «Татарстан – Новый Век» телеканал «Телевидение «Татарстан – Новый Век»	19.02.2024 11:00-11:40 №1 22.02.2024 11:00-11:40 № 2 26.02.2024 11:00-11:40 № 3 29.02.2024 11:00-11:40 № 1 01.03.2024 11:00-11:40 № 2 04.03.2024 11:00-11:40 № 1 07.03.2024 11:00-11:40 № 2 11.03.2024 11:00-11:40 № 3 14.03.2024 11:00-11:40 №1	19.02.2024 11:00-11:40 №3 22.02.2024 11:00-11:40 № 1 26.02.2024 11:00-11:40 № 2 29.02.2024 11:00-11:40 № 3 01.03.2024 11:00-11:40 № 1 04.03.2024 11:00-11:40 № 2 07.03.2024 11:00-11:40 № 3 11.03.2024 11:00-11:40 № 1 14.03.2024 11:00-11:40 №2	19.02.2024 11:00-11:40 №1 22.02.2024 11:00-11:40 № 2 26.02.2024 11:00-11:40 № 3 29.02.2024 11:00-11:40 № 1 01.03.2024 11:00-11:40 № 2 04.03.2024 11:00-11:40 № 1 07.03.2024 11:00-11:40 № 2 11.03.2024 11:00-11:40 № 3 14.03.2024 11:00-11:40 №1
ОАО «Татарстан – Новый Век» радиоканал «Радио «Татарстан – Новый Век»	20.02.2024 11:00-11:40 № 3 21.02.2024 11:00-11:40 № 1 27.02.2024 11:00-11:40 № 2 28.02.2024 11:00-11:40 № 3 01.03.2024 11:00-11:40 № 1 05.03.2024 11:00-11:40 № 3 06.03.2024 11:00-11:40 № 1 12.03.2024 11:00-11:40 № 2 13.03.2024 11:00-11:40 № 3	20.02.2024 11:00-11:40 № 2 21.02.2024 11:00-11:40 № 3 27.02.2024 11:00-11:40 № 1 28.02.2024 11:00-11:40 № 2 01.03.2024 11:00-11:40 № 3 05.03.2024 11:00-11:40 № 2 06.03.2024 11:00-11:40 № 3 12.03.2024 11:00-11:40 № 1 13.03.2024 11:00-11:40 № 2	20.02.2024 11:00-11:40 № 1 21.02.2024 11:00-11:40 № 2 27.02.2024 11:00-11:40 № 3 28.02.2024 11:00-11:40 № 1 01.03.2024 11:00-11:40 № 2 05.03.2024 11:00-11:40 № 1 06.03.2024 11:00-11:40 № 2 12.03.2024 11:00-11:40 № 3 13.03.2024 11:00-11:40 № 1
АО «ТАТМЕДИА» телеканал «Телекомпания «Чаллы-ТВ» («Телекомпания «Челны-ТВ»)»	19.02.2024 18:25 №3, 19:25 №1 20.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 22.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 26.02.2024 18:25 №2, 19:25 №3 27.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 29.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 01.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 04.03.2024 18:25 №2, 19:25 №3 05.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 07.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 11.03.2024 18:25 №2, 19:25 №3 12.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №1, 19:25 №1 14.03.2024 07:00 №2, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №2	19.02.2024 18:25 №1, 19:25 №2 20.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 22.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 26.02.2024 18:25 №3, 19:25 №1 27.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 29.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 01.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 04.03.2024 18:25 №3, 19:25 №1 05.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 07.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 11.03.2024 18:25 №3, 19:25 №1 12.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №2, 19:25 №2 14.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3	19.02.2024 18:25 №2, 19:25 №3 20.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 22.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 26.02.2024 18:25 №1, 19:25 №2 27.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 29.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 01.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №2 04.03.2024 18:25 №1, 19:25 №2 05.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №2, 19:25 №3 07.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2, 18:25 №3, 19:25 №1 11.03.2024 18:25 №1, 19:25 №2 12.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1, 18:25 №3, 19:25 №3 14.03.2024 07:00 №1, 07:25 №3, 18:25 №1, 19:25 №1
АО «ТАТМЕДИА» радиоканал «Буа FM»	20.02.2024 18:00 №2 22.02.2024 18:00 №3 27.02.2024 18:00 №1 29.02.2024 18:00 №2 04.03.2024 18:00 №3 06.03.2024 18:00 №1 11.03.2024 18:00 №2 13.03.2024 18:00 №3	20.02.2024 18:00 №1 22.02.2024 18:00 №2 27.02.2024 18:00 №3 29.02.2024 18:00 №1 04.03.2024 18:00 №1 06.03.2024 18:00 №2 11.03.2024 18:00 №3 13.03.2024 18:00 №1	20.02.2024 18:00 №3 22.02.2024 18:00 №1 27.02.2024 18:00 №2 29.02.2024 18:00 №3 04.03.2024 18:00 №2 06.03.2024 18:00 №3 11.03.2024 18:00 №1 13.03.2024 18:00 №2
АО «ТАТМЕДИА» радиоканал «Радио «Кунел» (Радио Настроение)	19.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 21.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 22.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 26.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 28.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 29.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 01.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 04.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 06.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 07.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 11.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 13.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 14.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2	19.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 21.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 22.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 26.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 28.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 29.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 01.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 04.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 06.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 07.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 11.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 13.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 14.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1	19.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 21.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 22.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 26.02.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 28.02.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 29.02.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 01.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 04.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 06.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 07.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3 11.03.2024 10:10 №1, 10:30 №2, 18:30 №3, 20:30 №1 13.03.2024 10:10 №2, 10:30 №3, 18:30 №1, 20:30 №2 14.03.2024 10:10 №3, 10:30 №1, 18:30 №2, 20:30 №3
АО «ТАТМЕДИА» радиоканал «Биектау FM»	19.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 20.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 22.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 26.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 27.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 29.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 01.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 04.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 05.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 07.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 11.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 12.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 14.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3	19.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 20.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 22.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 26.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 27.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 29.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 01.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 04.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 05.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 07.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 11.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 12.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 14.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1	19.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 20.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 22.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 26.02.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 27.02.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 29.02.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 01.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 04.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 05.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 07.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2 11.03.2024 08:00 №3, 12:00 №1, 17:30 №2, 18:00 №3 12.03.2024 08:00 №1, 12:00 №2, 17:30 №3, 18:00 №1 14.03.2024 08:00 №2, 12:00 №3, 17:30 №1, 18:00 №2
АО «ТАТМЕДИА» телеканал «Нижнекамская телерадиокомпания» (НТР)»	19.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 20.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 21.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 26.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 27.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 28.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 01.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 04.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 05.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 06.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 11.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 12.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 13.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2	19.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 20.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 21.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 26.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 27.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 28.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 01.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 04.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 05.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 06.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 11.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 12.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 13.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3	19.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 20.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 21.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 26.02.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 27.02.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 28.02.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 01.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 04.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 05.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 06.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1 11.03.2024 07:00 №2, 07:25 №3 , 18:25 №1, 19:25 №2 12.03.2024 07:00 №3, 07:25 №1 , 18:25 №2, 19:25 №3 13.03.2024 07:00 №1, 07:25 №2 , 18:25 №3, 19:25 №1
АО «ТАТМЕДИА» радиоканал «Арча»	19.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 20.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 22.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 26.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 27.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 29.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 01.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 04.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 05.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 07.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 11.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 12.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 14.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3	19.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 20.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 22.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 26.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 27.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 29.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 01.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 04.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 05.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 07.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 11.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 12.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 14.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1	19.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 20.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 22.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 26.02.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 27.02.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 29.02.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 01.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2 04.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 05.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 07.03.2024 08:30 №2, 12:30 №2, 13:30 №1, 19:30 №2 11.03.2024 08:30 №3, 12:30 №1, 13:30 №2, 19:30 №3 12.03.2024 08:30 №1, 12:30 №2, 13:30 №3, 19:30 №1 14.03.2024 08:30 №2, 12:30 №3, 13:30 №1, 19:30 №2
АО «ТАТМЕДИА» радиоканал «Нократ дулкыннары (Вятские волны)»	19.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 20.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 22.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 26.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 27.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 29.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 01.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 04.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 05.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 07.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 11.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 12.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 14.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45	19.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 20.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 22.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 26.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 27.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 29.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 01.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 04.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 05.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 07.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 11.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 12.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 14.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:46	19.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 20.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 22.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 26.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 27.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 29.02.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 01.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 04.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 05.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 07.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 11.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 12.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:45 14.03.2024 07:15, 07:45, 12:15, 12:47

vk.com

ИСКЕ ЯҢА КАПКЫН

Яшәргә өйрәнәбез

Алдаучысы да, алданучысы да бетми. Сүзебез – финанс пирамидалары турында. Күпме генә сөйләсәк тә, язсак та, белгечләр аңлатырга тырышса да, җиңел табышка кызыгып, ярык тагарак янында калучылар саны кимеми. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, быелтыр акчага бәйле кырын эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр, 2022 елдагы саннар белән чагыштырганда, 15 процентка күбрәк булган.

Кәкре каенга терәтү

Хәтерләсәгез, моннан берничә ел элек Татарстанда бер финанс пирамидасы җимерелеп, күпме кеше акчасын югалтты. Язмыш шуклыгыдыр инде: юрист булып эшләүче Казан егете Айнур Гәрәевнең дә 60 мең сум акчасы кырыгалдарлар кулында кала.

Сан

➤Россия банкы узган ел **5,7** меңнән артык финанс пирамидасын һәм легаль булмаган финанс хезмәтләре күрсәтүчеләрне ачыклаган. Бу **2022** ел белән чагыштырганда **15,5** процентка күбрәк.

➤Социаль челтәрләрдәге **3** меңнән артык сәхифә, канал һәм чат-ботлар ябылган. Хокук саклау органнары **2023** елда пирамида оештыручыларга карата **125**тән артык җинаять эше кузгаткан.

– Әлбәттә, мин дә, барысы кебек үк, җиңел акчага, зур табышка кызыктым инде. Ул вакытта миңа 27 яшь иде, – ди Айнур. – Хәзер үземнең шундый беркатлы булуымны көлеп искә алам. Ярый әле югалткан акчам ул кадәр күп түгел иде. Башкалар кебек, фатир, машина сатып, бурычка батып, булган мөлкәтемне анда тыкмадым. 60 меңнең яртысы дустымныкы иде. Буш торган, «кара көн»гә дип тоткан акчабыз иде ул. Имеш, зур керем алгач, бизнес ачарбыз, дип хыялландык. Хәзер инде күп нәрсәгә шикләнеп карарга өйрәндем. Финанс ягыннан никадәр белемсез икәнебезне аңладым.

Айнур сүзләренчә, аны диндә килеш шушындый пирамидаларда катнашкан кешеләр аеруча шаккатырган.

– Мин баш-аягым белән дингә чummаган, намаз укымыйм, ураза тотмыйм, шулай да Аллаһы Тәгаләгә ышанам. Намаздагы, яулыклы, түбәтәйле кешеләрнең шушындый пирамидаларга ышанып акча тапшырганнарын гаҗәпләнеп күзәтә идем. Алар андый җирдә аз түгел. Кредит та гөнаһ булганны, монысын хәләл дип уйлыйлармы икән? – дип сөйләде ул.

Фикер

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы:
– Гадел эшмәкәрлек, сату-алу динебездә бик хуплана. Булачак хатыны Хәдичә белән танышканда, рәсүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә гади сатучы була. Рәсүлебез бер хәдистә: «Гадел эшмәкәр кыямәт көнендә һәм җәннәттә пәйгамбәр белән бергә булачак», – ди. Әгәр шушы эшмәкәрлек, сатып алып акча эшләү гадел булмаса, ул кеше тәмуг утларында яначак. Шуңа күрә кешедән алдап акча алу, аларны кире кайтарырга вәгъдә итеп, юкка чыгуга корылган эшмәкәрлек тыелган, хәрам санала. Ул урлау белән бер. Шуңа күрә финанс пирамидалары да, челтәрле маркетинг та дин тарафыннан тыелган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдистә: «Әгәр дә кем изгелеккә чакырса, өндәгән кешегә дә, кылган кешегә дә савабы бер үк дәрәҗәдә булачак. Әгәр дә кем гөнаһка чакырса, өндәгән кеше дә, үтәгән кеше дә гөнаһлы булыр», – дигән. Шуңа күрә, ышанып, акчасын тапшырган кешенең бу очракта, иншаллаһ, гөнаһы юктыр. Аны алдаган, шушы тозакка чакырган кешегә гөнаһы бик зур була.

Пирамидамы, түгелме?

Өреп капсаң, ризык пешерми. Бу кагыйдәне финанс мәсьәләсендә куллансак та, хәерлегә генә. Булган малны теләсә нинди шикле юнәлешләрдә туздырмас өчен, кайбер киңәшләрне истә тоту зыян итмәс.

ШИКЛЕ ФИНАНС ОЕШМАСЫ БИЛГЕЛӘРЕ

1. Зур табыш вәгъдә итү.
2. Табышны «100 процент булачак» дип ышандыру.
3. Агрессив реклама (интернетта, матбугат чараларында).
4. Финанс оешмасының җитәкчелеге, хуҗасы турында, аларның кайда булулары хакында мәгълүмат булмау.
5. Акча түләү шушы финанс «өермә»сенә яңа кешеләрне чакыру хисабына башкарылу.
6. Финанс оешмасының үз акчасы, активлары булмау.
7. Лицензиясе, Россия банкы реестрында мәгълүмат табылмау.

Мошенниклар тозагына эләгүегезне аңлап алсагыз, ашыгыч рәвештә хокук саклау органнарына гариза языгыз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Яшәеш

Бәхетле куыш

Татарстан Россия төбәкләре арасында авыл ипотекасын алу буенча беренче урынга чыккан. Узган ел әлеге максатларга 4 млрд сум акча бирелгән һәм авылда, район үзәгендә яшәүче меңнән артык гаилә яшәү шартларын яхшырта алган, дип хәбәр итә Росреестрның Татарстан буенча бүлеге.

Бәхетлеләр арасында Лаеш районының Сокуры авылында яшәүче Аида һәм Рөстәм Нагумановлар гаиләсе дә бар. Алар өч бала тәрбияләп үстерә. Моңа кадәр шушы авылда ук ике бүлмәле фатирда яшәгәннәр. Программада катнашып, фатирларын ике катлы зур йортка алыштырганнар.

– Без әзер йорт сатып алдык, хәзерге вакытта анда ремонт ясыйбыз. Документларны тапшырып, нибары ике-өч ай узганнан соң ук, зур йортлы булдык. Без бик канәгать. Яшь гаиләләр өчен менә дигән мөмкинлек дип саныйбыз без аны. Өч бала белән ике бүлмәле фатирыбыз кысан була башлаган иде. Ә монда бик иркен, бик матур, сөенеп туя алмыйбыз, – диде Аида Нагуманова.

Гомумән алганда, программа гамәлгә ашырыла башлаганнан бирле, татарстанлылар 11,1 млрд сум кредит алган һәм 4200 гаилә яшәү шартларын яхшырткан.

– Моңа кадәр Татарстан халкы 3 млн сумга кадәр генә кредит ала ала иде, 2023 елдан аның күләмен 6 млн сумга кадәр җиткерделәр. Әгәр ир белән хатын икесе дә үз-үзләрен кайгырта алырлык хәлдә, кредит алырга мөмкинлек бирә торган хезмәт хакы алып эшлиләр икән, аерым-аерым да рәсмиләштерә алалар. Шулай итеп, бер гаиләгә 12 млн сумга кадәр кредит бирелә дигән сүз, – дип аңлатты республиканың беренче урынга чыгуын Дәүләт Советы депутаты, Россельхозбанкның Татарстан төбәк филиалы директоры Ләлә Кудерметова.

Моннан тыш, программада катнашу шартлары да елдан-ел үзгәртелеп, яңартылып тора. Әйтик, программа гамәлгә ашырыла башлаган 2020 елда фатирны аз һәм күпфатирлы йортлардан да, төзелә торганнардан да алырга мөмкин иде. Бераздан азкатлы йортлардан гына фатир алырга рөхсәт ителде. Аннан соң бары тик йортлар гына алу мөмкинлеген калдырдылар. Узган елдан исә биш каттан артмаган йортлардан фатир алу мөмкинлеген кайбер районнарга гына бирделәр. Әйтик, мондый фатирлар Арча, Буа һәм Мөслимдә сатылган.

Авыл ипотекасы алырга теләүчеләр өчен тагын бер кызыклы мәгълүмат: хәзер йортны алганнан соң, яки йорт төзелеп беткәннән соң алты ай узгач, әлеге адрес буенча теркәлү мәҗбүри. Һәм моны һәр өч ай саен раслап барырга кирәк. Расланмаган очракта, процент ставкасы коммерциялегә күчә. Димәк, авыл ипотекасын алу шартлары катлаулана, ләкин әлеге программаны гамәлгә ашыручылар сүзләренчә, бу файдага гына.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәсми мәгълүматларга караганда, елдагыча, авыл ипотекасы буенча фатир алучылар, йорт төзүчеләр Казанга якын булган районнарда – Лаеш, Питрәч һәм Биектауда күбрәк. Ә менә узган ел Азнакай, Баулы, Спас, Кама Тамагы, Кайбыч, Минзәлә, Нурлат, Яңа Чишмә районнарында бер генә кеше дә әлеге программада катнашмаган.

– Бу районнар программада катнашмаган яки аларга кредит бирелмәгән дигән сүз түгел, аларда йортлар төзелмәскә дә мөмкин. Программа башлыча төзелеп беткән йортлар алуга юнәлдерелгән. Шуңа бәйле рәвештә, мәшәкатьлерәк, – дип аңлатты әлеге районнарда бер генә катнашучы да булмауны Ләлә Кудерметова. – Гомумән алганда, программада катнашырга теләп мөрәҗәгать итүчеләр саны кредит алучыларга караганда бермә-бер артыграк. Мин Казанга якын булган районнардан гына фатир алалар, дип әйтмәс идем. Үзәктән читтәрәк урнашкан район үзәкләрендә дә программа яхшы эшли. Әйтик, Алабуга районында – 28, Әлмәттә – 17, Актаныш районында 7 гаилә авыл ипотекасы буенча яшәү шартларын яхшырткан.

Программада катнашучыларның күпчелеге (90 проценты) әзер йортларны сатып алырга тели икән. Калганнары фатир алырга яки йортны үзләре салып керергә теләк белдерә, ди.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Без бел(мә)гән тарих

Өлкән буын арасында башкалабыздагы Горький исемендәге Үзәк парктан Казансу буена илтә торган канатлы юлны хәтерләүчеләр күптер әле. Эшләүдән туктагач та, аның калдыклары парк артында озак «яшәде». Хәзер исә канатлы юлны кабат торгызу турында сүз кузгатылды.

КАНАТЛЫ ЮЛ

Бишбалта тарихын өйрәнүче **Гарәфетдин ХИСАМЕТДИНОВ**ның бу җәһәттән күптән әйтә килгән үз фикерләре дә бар. Форсаттан файдаланып, канатлы юлның тарихы, мөмкинлекләре турында укучыларыбызга да җиткерергә булдык.

:: Гарәфетдин абый, бу юлы канатлы юл безне кайларга «илтеп ташлар» икән?
– План буенча канатлы юл 2024 елның июль аенда төзелә башлап, ел ярым эчендә гамәлгә керергә тиеш. Ул Горький паркы янында урнашкан «Корстон» сәүдә үзәге яныннан башланып, «Урам» паркы янында туктап, пассажирларны «Ак Барс» стадионына илтеп куячак. Бу юлның озынлыгы 2800 метрдан артыграк, ара якынча 10 минутта үтеләчәк, сәгатенә 2400 кешегә хезмәт күрсәтеләчәк.

:: Узган ел ахырында Михаил Любимовның Казанда төзеләчәк канатлы юл турындагы ТНВ каналыннан күрсәтелгән «Воздушные замки» фильмы канәгатьләнү хисе калдырмады, дигән идегез. Сәбәбе?
– Мине борчыган нәрсә шул булды: фильмда чыгыш ясаган инсаннар канатлы юлның тарихын җитәрлек дәрәҗәдә сөйләмәде һәм, ни өчендер, Казаныбызга бәйле фактлар юкка чыгарылды. Югыйсә ул Татарстан тарихында яңалык түгел бит.

:: Бу тарих турында халыкканиләр җиткерә аласыз?
– Канатлы юлның исеме дә татар теленнән алынган. Ерактан караганда, ике ярны тоташтыручы аркан, бау, трос күренми. Йөкне алып килүче әрҗә, кәрзин канатлы кебек тоела. Канат сүзен русчага тәрҗемә итсәк, ул ике төрле мәгънәне аңлата: канат – крыло, канат – аркан. Икесенең дә исеме җисеменә туры килеп тора. Татарстанда беренче канатлы юл 1960–1964 елларда башкаладагы Горький исемендәге паркта, шәһәр комитетының беренче секретаре Рәшит Мусин тәкъдиме буенча эшләнә башлый. Аны республикабызда машина төзелешенә нигез салучы, СССРдагы бердәнбер канатлы юллар һәм тимер тасмалы конвейерлар эшләүче «Урак һәм Чүкеч» заводы ясый һәм шәһәргә бүләк итә. Ул паркның иң ерак очында, каеклар рәвешендә эшләнгән таганнар яныннан башланып, Казансуга ял итүчеләрне, кунакларны, чаңгыда шуучыларны, һәвәскәр балык тотучыларны аска, Подлужный урамына илтте. Озынлыгы – 300 метр, биеклеге 20 метр була. Өч тимер баганага беркетелгән, канатлы юлга эленгән ике кешелек, тимердән эшләнгән кабиналардан тора иде. Кызганыч, бүген завод та юк: 2015 елның мартында янгын аны көлгә әйләндерде, ә парктагы канатлы юлның гомере 1990 нчы елларда, Миллениум күпере төзелә башлагач бөтенләйгә өзелде.

:: Казандагы канатлы юлның гомере ни өчен шулай кыска булды икән?
– Беренчедән, канатлы юлны балансказ алмыйлар, куркынычсызлыкны кисәтү йөзеннән, карап эшләтүче белгечләр билгеләнми һәм ремонт ясау базасы булдырылмый. Проблемалар килеп чыкса, гадәттә заводтан ярдәм сорыйлар иде. Әмма бу чорда заводларга бизнес белән шөгыльләнү катгый рәвештә тыелды. Шул рәвешле сафтан чыга барган җиһазларны төзәтүче булмады. Икенчедән, канатлы юлның башын транспорт тукталышы янына куйсалар, кешеләр күбрәк килер иде. Парк артына урнаштырылу сәбәпле, ул, чыннан да, халыкка якын түгел иде.

:: Бу җәһәттән «Урак һәм Чүкеч» заводының үз планы да булган...
– Әйе. Завод үзләре төйи, үзләре бушата торган вагоннар белән йөк ташый торган канатлы юллар җитештерде. Алар бөтен ил буйлап кулланылды. Соңрак пассажирларны, туристларны йөртү өчен дә чыгарырга әзерләнгән иде. Уракчы (Аракчино) төбәгеннән Югары Ослан авылына Идел елгасы аша кешеләрне йөртү иде безнең хыял. Канатлы юлларның куркынычсызлыгы Ростехнадзор таләпләрен канәгатьләндерергә, боралакларныкына һәм самолетларныкына тиңдәш булырга тиеш иде. Әмма сәясәт үз кагыйдәләрен кертте. Завод эшчеләре бу эшләрне төрле төбәкләргә барып эшләргә мәҗбүр булдылар. Әзерләнгән җиһазлар да шунда күчерелде. 1967 елда Тяжмаш министрлыгына кергән башка заводлар белән канатлы юлны Кырымда төзи башлыйлар. 1987 елда Карайөздән (Мисхор) Ай Петри тавына 2980 метр озынлыктагы юлны куллануга тапшыралар. Ул бүген дә эшли, теләүчеләрне 15 минут эчендә тау башына менгереп куя.

:: Бәлки, канатлы юл табыш китерә алмый дип исәпләнгәндер?
– Беренчедән, һичшиксез, бу социаль яктан отышлы, уңайлыклар тудыра, араларны якынайта, юлларны кыскарта, туристларга тарих белән танышырга, шәһәр белән хозурланырга ярдәм итә. Икенчедән, икътисад өлкәсендә югары белемле сәнәгать белгечләренең күрсәткечләре бар: элек рентабельлелек буенча беренче урында – зур йөк, ашлык, контейнер ташучы океанда, диңгездә йөрүче танкерлар, икенче урында канатлы юллар иде. Торба буенча газ һәм кара алтын куучылар барлыкка килгәч, канатлы юллар өченче урынга күчте. Димәк, табышлымы-юкмы дип сүз куерту бөтенләй урынлы түгел.

Сан

Россиядә **400**гә якын канатлы юл эшли, шуларның **109**ы – ял йортларында, курортларда, **49**ы – Азия ягында, калганнары йөк ташуда кулланыла. Гомуми озынлыгы **500** километрдан артык.

:: Канатлы юл турында сезнең үз фикерегез дә бар бит әле...
– Канатлы юлны түбәндәге маршрут белән эшләсәләр, отышлы булыр иде дип уйлыйм: Казан Кирмәне – Бишбалта (Бакалда йокымы, Адмираллык бистәсе, Җәмигъ мәчете) – Уракчы (Аракчино), Барлык диннәр гыйбадәтханәсе – Югары Ослан – Таҗик (Мәркиз) утравы – Казан Кирмәне. Бу юнәлеш тәкъдим ителгән «Көмеш дага» брендының бер өлеше булыр иде.

Мин шулай ук төзеләчәк Җәмигъ мәчетен яңа төр транспорт – «Оч бөке» белән Болгар шәһәрендәге дини үзәкләрне тоташтыру турында да уйланам. Бу хакта язып та чыккан идем. Моның ни-нәрсә икәнен аңлатып бирүне сораучылар да булды. Русча бу төр транспортны «Капсула лёт» дип атадым. Аны 2012 елда Америкада Илон Маск Сан-Франциско белән Лос-Анджелес шәһәрләрен тоташтыру өчен тәкъдим иткән булган. «Hyperloop» («Вакуум поезды») проекты диаметры 3 метрлы торба эчендәге 25–30 кеше утырган капсуланы күз алдында тота. Тизлеге – бер сәгатькә 1000 километр. Кытайлар исә Американы узып киткәннәр, аларның Гуанчжоу белән Шанхай арасында сынау үтүче «Оч бөке»ләренең тизлеге тавыш тизлегенә якын, сәгатенә 1200 километр, салонда утыручылар саны да күбрәк. Бездә дә бу проект тормышка ашса, Казан – Болгар арасын, тәүлекнең һәм табигатьнең нинди булуына карамастан, 10–15 минутта үтәргә мөмкин булыр иде, ә Казан – Чаллы арасына 20–25 минут кирәк булачак. Хыяллар кайчан да булса тормышка ашар, канатлы юллар төзүче завод, бәлки, Татарстанда да барлыкка килер дип өметләнәм, чөнки технология өлкәсендәге яшен тизлегендә бара торган үзгәрешләр шул хакта сөйли.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Карлар ява...

Бу темага, гадәттә, кулына яңарак кына каләм алган кешеләр яза. Беренче шигырьләр шул хакта була. Беренче нәсерләр, хикәяләр... Кайберләре уңышлы да килеп чыга, күбесе, кар өеме булып, аяк астына төшә дә вакыт үтү белән эреп ага.

Ләкин быел карлар чынлап та күбрәк яуды. Һәрхәлдә, мондый күренешнең хәтсездән булганы юк иде. Шуңа шәһәр хакимиятләренә урамнарны-сукмакларны тазарту өчен бүленгән акчаның бер өлеше, чынлап та, кар җыештыруга китә башлады бугай. Кар көрәгән кешеләрне, юл чистартырга чыккан трактор-машиналарны күргәч: «Бәрәч, болар һаман исән икән әле», – дип куясың. Узган кышларда күзгә чалынмагач, аларны күрү динозаврлар белән очрашкандагыдай тәэсир калдыра. Хис-тойгылар үрә баса.

Шуңадыр инде интернетта да, матбугатта да кар турындагы язмалар мыжгып тора. Гәзит-журналлар юл тазартучыларның үзләре көн дә эшләргә тиешле эшне ничек тырышып башкаруын чагылдырган мәкаләләр бастыра. Үз эшен җиренә җиткереп башкаручылар дефицит заман булгангамы икән, ул язмалар сенсация, гайре табигый хәл кебек укыла. Интернетта җырлар, шигырьләр, анекдотлар пәйда була. Аларга комментлар язалар, лайклар куялар. Халыкның моңа кадәр бер дә кар күргәне булмаган диярсең. Менә мин дә шулар рәтенә кушылырга булдым әле. Кар күргән бар инде минем барлыгын, тик менә шәһәр урамнарында кар көрәүчеләр, юл чистартучылар чынлап та сагындырган икән. Рәхмәт аларга. Үз эшләрен эшләгән өчен. Гомумән, үз эшен җиренә җиткереп башкаручы һәр кешегә рәхмәт. Кар көрәүчеләргә – аеруча. Әгәр алар булмаса... Мин менә шундыйрак хәлне күз алдына бастырдым...

Иртән... Иртәнме, кичме инде шунда... Баскан килеш урамда йоклагансыңмы... Уянып китәсең. Һәм үз күзләреңә ышана алмый торасың. Бөтен дөньяны кар күмеп киткән... Син япа-ялгыз калгансың... Күктә – болытлар, җирдә – кар. Һәм син.

Нәрсә эшләргә, ни кылырга белмисең икән, кай яккадыр атларга кирәк. Урыныңда гына торырга ярамый, югыйсә эчең поша башлый, башыңа котсыз уйлар килә, күңелеңне караңгылык үрә. Кай яккадыр атларга. Атлау ул – хәрәкәт. Хәрәкәт – иң зур юаныч, чөнки хәрәкәтләнә аласың икән, димәк, син исән.

Вәт, син кар ерып атлыйсың хәзер. Үзеңнең кая барганыңны да белмисең. Тик барырлык мөмкинлегең бар икән, атларга кирәк. Кая да булса барып чыгачаксың. Кая барганыңны белмәү – фаҗига түгел. Бөтен кеше дә шушы халәттә яши.

– Кая барасың?

– Кибеткә, икмәк алырга.

Дөресме? Түгел. Кибеткә керү белән, алсуланып торган алмаларга кызыга, әфлисун да алып сала, колбаса да кирәк, йомыркасы да бетеп килә, әнә тегендә акция буенча бик арзанга тагы нидер саталар... Шулай күзенә эләккән нәрсәләрне җыя-җыя-җыя да икмәк алырга онытып чыгып китә.

Табибка бара кеше. Дәваланырга. Табиб карый, тикшерә... Рентген үтә теге кеше, анализлар бирә, узига төшә, уколлар, дарулар сатып ала. Уколлар кадый, дару эчә. «И әйбәт карыйлар!» – дип сөенә. Ә чире бетми. Чирең бетмәгәч, дәвалану түгел бит инде бу. Димәк, ул табибка акча түләргә генә бара.

Шул рәвешле, беркем дә үзенең кая барганын, нәрсә эшләгәнен төгәл белми. Бу начар түгел, киресенчә, өстенлек бу, аның да иң зуры. Кая барганыңны белмисең икән, сиңа кай тарафка атласаң да барыбер. Шулай булырга тиеш. Тик менә монда инде ниндидер могҗиза килеп чыга. Кеше үз юлын дәвам иттерергә тели. Син инде көнозын кар ерып килгәнсең, әллә күпме көч куйгансың, вакытыңны сарыф иткәнсең, хәзер кире борыласы килми, башка юнәлешне сайлыйсы да килми. Үз юлыңны дәвам иттерсәң генә, нәрсәгәдер ирешерсең кебек тоела. Ә алда юл юк.

Кирәкми алай эшләргә. Кирегә борыл. Көрчеккә яки һәлакәткә таба юл алгансың икән, кире борылуың хәерле. Күпме иртәрәк борыласың, шулкадәр яхшырак. Кая барганыңны да белмәгән чакта бигрәк тә.

Ә «кирегә юл юк» дигән сүз дөрес түгел. Бар. Һәм бик гади генә: артка борыласың да килгән эзең буйлап алга җилдерәсең. «Алга!» дигән сүзне абсолют юнәлеш дип кабул итәргә ярамый, без кайсы якка барабыз, шул – алгы як.

Бу – әдәбиятка, сәнгатькә яки сәясәткә, икътисадка гына түгел, бөтен өлкәгә дә кагыла торган гади канун бугай. Шул исәптән кар каплаган дөньяда калган ялгыз адәмгә дә.

Ышыкланыр урын кирәк кешегә беренче нәүбәттә. Бар дөньяны кумәрдәй булып карлар яуганда бигрәк тә. Ашар ризык, кияр кием кирәк. Ә аларны син беркая китмичә, бер үрне яуламыйча да булдыра аласың. Тормышны дәвам иттерү өчен, җиңүләр һәм уңышлар мәҗбүри түгел, бары тик көндәлек мәшәкатьләреңне үз нәүбәтендә җиренә җиткереп хәл итәргә генә кирәк.

Ә карлар ява инде ул. Ел әйләнәсе. Кайберләре күзгә күренми генә.

Марат КӘБИРОВ

ЧЫКМАСЫН УЙМАК

РОССИЯДӘ БАЛАЛАР УЕНЧЫКЛАРЫНА ГОСТ ТАЛӘПЛӘРЕ КЕРТЕЛӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Исе, төсе, тавышы... Якын арада Россиядә балалар уенчыкларын әнә шулай һәр яклап тикшерә башламакчылар. Роскачество идарәсе, балалар уенчыклары өчен махсус таләпләр кертеп, аларны ГОСТ нигезендә теркәмәкче. Бу тәкъдим уңаеннан фикер алышулар узган инде.

Азнакай районының Тымытык авылында яшәүче Ләйсән Шәяхмәтова әлеге яңалыкны шатланып кабул иткән. Алты бала әнисе үзе дә балаларына уенчык сайлауга җаваплы карый икән.

– Хәзерге балалар курчак, йомшак уенчыкка гына риза түгел шул. Аларга шул ук Хагги-Ваги, «сиреноголовый» кебек берсеннән-берсе куркыныч уенчыклар кызык. Аларның балага зыян гына салуы көн кебек ачык. Шуңа күрә бу уенчыкларны да яхшылап тикшереп, тыйсыннар иде. Уенчык тәрбия чарасы да булып тора бит. Шәхсән үзем уенчык сайлаганда аның нәрсәдән эшләнүенә игътибар итәм. Аның чыдамлы, уңай, матур булуы да мөһим, – ди Ләйсән.

Россия Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе урынбасары Татьяна Буцкая белдерүенчә, яңа ГОСТ таләпләре дә, иң беренче чиратта, балаларның сәламәтлеген, психикасын саклау өчен кертелә. Ник дигәндә, яңа кагыйдәләр нигезендә уенчык баланы куркытмаска, психикасына зыян салмаска, аңарда үз-үзенә кул салу, җенес алыштыру кебек начар уйлар уятмаска тиеш.

Алдан ук искәртеп куйыйк. Әлеге ГОСТ таләпләре ирекле рәвештә кертелә. Ягъни аларны үтәү-үтәмәү һәр җитештерүченең үз намусында кала. Ә менә дәүләт заказы аша балалар бакчалары, балалар оешмалары өчен уенчык җитештерүчеләргә бу таләпләрне үтәү мәҗбүри булачак. Белгечләр исә бу таләпләргә һәркем колак салырга тиеш дип саный.

Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов бу эшнең нәтиҗәле булачагына шикләнеп карый. «Уенчыкка куелган таләпләр белән бергә аның бәясе дә артырга мөмкин. Сыйфаты барыбер шул ук калачак», – дип саный ул.

Бүген Россиядә кибетләрдә сатылган лицензияле уенчыкларның 40 проценттан артыгы сыйфатсыз. Балалар товарлары индустриясе ассоциациясе белгечләре шулай ди. Уенчыкларга ГОСТ таләпләренең ни өчен кертелүе дә шуннан яхшы аңлашыла.

КФУдагы Психология һәм белем бирү институтының педагогик психология кафедрасы өлкән укытучысы Динара Хәмәтвәлиева фикеренчә, бу таләпләргә балалар бакчасына уенчык китерүче оешмалар гына түгел, ата-аналар да колак салырга тиеш.

– Балалар кулына эләккәнче, уенчыклар тикшерү узарга тиеш. Аның сәламәтлеккә, психикага зыян саламы-юкмы икәнлеген тикшерергә кирәк. Бүген балалар күбрәк популяр булган, шул ук «Ютуб»та әйләнгән видеолардагы персонаж рәвешендәге уенчыкларны алдырта бит. Алар күп очракта балага зыян китерә, – ди белгеч. – Уенчыкның баланың яшенә туры килүе дә мөһим. Шул ук «Барби» курчагында ничәмә-ничә буын үсте. Ул чорда үз яшенә туры килгән курчак сайлау мөмкинлеге юк иде. Ә бит «Барби» курчагының гәүдә төзелеше гадәти хатын-кыз стандартларына туры килми. Шуңа күрә аны эталон итеп кабул иткән кыз баланың үсмерлек чорында психик проблемалар барлыкка килергә мөмкин. Ник дигәндә, бу чорда үсмер кыз балалар еш кына йөз-кыяфәтеннән канәгать булмый башлый.

Динара Хәмәтвәлиева сүзләренә караганда, бала өчен чынбарлыкны чагылдыра торган уенчыктан да яхшысы юк. Көндәлек тормыштагы рольләргә кереп уйный торганы аеруча яхшы икән.

– Агачтан ясалган файдалы уенчыклар бар. Бер яктан, алар ясалма материалдан (пластиктан) түгел, икенчедән, аларның төсләре гадәти. Мисал өчен бик кечкенә балаларга артык купшы төстәге уенчыклар алырга киңәш ителми. Ник дигәндә, алар әле бу яшьтә билгеле бер төсләрне генә кабул итә ала. Безнең тормыштагы рольләрне гәүдәләндергән уенчыклар да яхшы. Мәсәлән, әни һәм бала, аерым һөнәрләрне чагылдырган уенчыклар бала психикасына уңай йогынты ясый. Ул шул рольләрне үзендә сынап карый. Бу аның үсешенә дә уңай тәэсир итә, – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

НИНДИ УЕНЧЫК АЛМАСКА?

Бала сәламәтлегенә куркыныч тудыручы әйберләрнең өчтән берен уенчыклар тәшкил итә, ди Роспотребнадзор белгечләре. Кайсы уенчыклар аеруча куркыныч соң?

«Барби» курчагы. Иң еш алдап ясала торган бала уенчыкларының берсе. Тикшерү барышында белгечләр мондый төр уенчыкларның яртысыннан артыгында баланың репродуктив системасын, бавырын эштән чыгаручы фталат дигән зарарлы матдә тапкан.

Батарея ярдәмендә эшли торган уенчыклар. Белгечләр аларын да иң хәтәрләр рәтенә кертә. Ник дигәндә, мондый төр сыйфатсыз уенчыкларның батарея куышлыгында еш кына капкачны беркетә торган винт булмый. Бу исә – бала аны бернинди коралсыз җайлы гына ачып, батареяны йотарга мөмкин дигән сүз. Аның составындагы матдәләр сабыйның ашказанын яндыра ала.

Йомшак уенчык алганда аның җөйләре сүтелмәгән, аңа беркетелгән пластмасс күз, авыз-борынның нык булуына игътибар итәргә кирәк. Арзанлы йомшак уенчыкларның шушы пластик беркетмәләрендә дә еш кына алда телгә алынган фталат дигән зарарлы матдә була, ди белгечләр.

Һава шары, йөзү, коену өчен уенчыклар эшләнгән каучукта йоткылык, тире яман шеше килеп чыгу ихтималын арттыручы зарарлы матдә – нитрозамин булырга мөмкин.

Слайм, лизун, пластик балчык бүген замана баласының кулыннан төшмәгән иң популяр уенчыклар санала. Аларның составында натрий тетрабораты бар. Аның күләме тиешле нормадан артып китсә, алда телгә алынган уенчыкларны иснәгән баланың эчке әгъзалары пешәргә мөмкин.

Җырлый торган уенчыклар. Алардагы тавыш ешлыгы нормадан артып китсә, баланың начар ишетә башлавы бар.

Уйлы күңел уйлана

НИГЕЗ ТАШЫҢ НЫКМЫ?

Мин үлгәч, бу нигез бетә, монда яшәүче кеше булмый... «Салган» баштан шушындый фараз корган атаның «күрәзәлеге» аздан гына чынга ашмыйча кала. Ул вафат булгач, янгын чыгып, бөтен каралтылары көлгә әйләнә.

«Әти шулай дигән иде, монда яңадан өй салырга ярамас инде», – дип, балалары яңа нигез турында уйлана башлый. Тик төп нигездә хәсрәт булуын ишетүгә көне-сәгате белән кайтып җиткән туган апалары (әтиләренең бертуган сеңлесе) генә бу фикер белән килешә алмый.

– Ялгышасыз, балалар. Әтиегез гомердә дә андый сүз әйтә торган кеше түгел. Бала чактан шушы нигез дип яшәде, нык булсын дип, ташларына кадәр сайлый-сайлый тезде ул. Күрдегез бит, һәрчак бөтен каралтыгыз төзек булды. Янгын калдыкларын сүткәндә аларның ничек ныгытып, гомерлеккә дип беркетелгәнен күреп, авылдашлар да аптырады хәтта. Янгын чыкмаса, әле тагын шулкадәр тора иде бит, – ди ул. Шулай итеп нигездә кабат каралты-кура торгызырга күндерә һәм ярдәм дә итә. Санаулы ай эчендә яңа йортлы булган туганнары өчен ул алардан да ныграк сөенә. Шулай булмыйни: нигезләре бетмәде, үзләренеке-ләр яши, тормыш дәвам итәчәк бит!

...Нигез кадере турында нигәдер болай да күп уйланам мин. Бигрәк тә шушындый уйландыра торган хәлләр, вакыйгалар турында сөйләсәләр. Гадәттә, нигез турында аны йә югалтканнар (сатканнар), йә читтә җирсеп яшәгәннәр күбрәк уйлана. Әмма арада гомер буе туган нигезен саклап та, дәвамын кайгыртып яшәп тә, башкаларга да бу хакта онытырга ирек бирмәүче кешеләр дә очрый. Татарстанның Баш казые, вәгазьләр остасы Җәлил хәзрәт – әнә шундый танышларымның берсе. Аның идеясе, тырышлыгы белән дөнья күргән Бөрбаш авылы тарихына багышланган китап та тикмәгә генә «Саклагыз нигез ташын» дип аталмагандыр инде.

Беркөн каладагы танышларым Бөрбаш турында бер мәгълүмат сорады да, бәйрәм ялларында кеше борчымыйм инде дип, шушы китапны кулга алдым. Дөрестән дә, анда күңелеңдә туган һәр сорауга җавап табып була. Үземә кирәкле мәгълүматны тапкач та, китапны читкә куеп булмады. Сүз уңаеннан, элекке каләмдәшем, күп еллар район редакциясендә, аннан «Ватаным»да бергә эшләгән Бөрбаш кызы, танылган журналист Лилия Нурмөхәммәтова бу китапны чит-ятлар өчен дә укылышлы, әдәби әсәрдәй кызыклы итү өчен зур тырышлык куйган. Тарихи фактлар, бәян-фаразлар да, яралы язмышлар, шатлыклы вакыйгалар, авылдашлары истәлекләре дә... – бөтенесен бербөтен итеп бәйли алган ул. 610 битле китапта мәгълүмат та, уйландырырлык язмалар да бихисап.

«Чыганаклардан күренгәнчә, Бөрбаш авылының 400 елдан артык тарихы бар. Ничә буын туганнар шушы авыл үссен, яшәсен өчен көч куйган, үзләреннән өлеш керткән. Нинди генә авырлыклар белән очрашмасыннар – сынмаганнар, сыгылмаганнар, авылыбызны саклап, бүгенгә китереп җиткерә алганнар. Алар салган нигез ташларын саклау бүген безнең кулда, ә Бөрбашның нигез ташларын таратмау – киләчәк буынның изге бурычы», – дип, китапка кереш сүзендә үк берничә буынны бәйләрлек фикер-нәсыйхәт бирә Җәлил хәзрәт. Бөртекләп авыл тарихы, нигезләр тарихы (китапта нәкъ менә авылдагы нигезләр тарихы сизелерлек урын алган) турында язмалар туплаган Лилия дә, шушы авылда туып-үсмәсә дә, яшьли вафат булган әтисе Рафилнең туган авылына бик күп ярдәм күрсәткән, әлеге бик тә сыйфатлы, саллы китапны чыгаруның да матди ягын үз өстенә алган, «Әйбәт булсын, һәр нигез керсен, онытылып кала күрмәсен», – дип кайгыртып торган Нияз Галимуллин да шушы ук фикерне китапның беренче битеннән ахыргы битенә кадәр сеңдерергә тырышкан. Һәр урам, һәр йорт – һәр нигез тарихы шушы китап аша киләчәк буыннарга тапшырылган. Аны кулына алган һәркем: «Безнең нигез ташы ныкмы соң?» – дип уйланырлык булган ул.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 219

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+